МИНИСТЕРСТВО ЭКОНОМИКИ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ИКЪТИСАД МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

13.04.2022 Казан шәһәре №138

Кара металл һәм төсле металл калдыкларын әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату эшчәнлеген лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең Административ регламентын раслау турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «Кара һәм төсле металл калдыкларын әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату эшчәнлеген лицензияләү турында» 2012 елның 12 декабрендәге 1287 номерлы карары нигезендә боерам:

1. Кара һәм төсле металл калдыкларын әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату эшчәнлеген лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең кушымта итеп бирелгән Административ регламентын расларга

2. Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының түбәндәге боерыкларын үз көчен югалткан дип танырга:

«Кара металл һәм төсле металл калдыкларын әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату эшчәнлеген лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең Административ регламентын раслау турында» 2013 елның 26 августындагы 277 номерлы;

2013 елның 26 августындагы 277 номерлы Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы боерыгы белән расланган «Кара металл һәм төсле металл калдыкларын әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату эшчәнлеген лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең Административ регламентына үзгәрешләр кертү турында» 2014 елның 08 августындагы 289 номерлы;

2013 елның 26 августындагы 277 номерлы Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы боерыгы белән расланган «Кара металл һәм төсле металл калдыкларын әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату эшчәнлеген лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең Административ регламентына үзгәрешләр кертү турында» 2015 елның 19 мартындагы 134 номерлы;

2013 елның 26 августындагы 277 номерлы Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы боерыгы белән расланган «Кара металл һәм төсле металл калдыкларын әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату эшчәнлеген лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең Административ регламентына үзгәрешләр кертү турында» 2015 елның 03 июлендәге 317 номерлы;

2013 елның 26 августындагы 277 номерлы Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы боерыгы белән расланган «Кара металл һәм төсле металл калдыкларын әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату эшчәнлеген лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең Административ регламентына үзгәрешләр кертү турында» 2016 елның 16 мартындагы 70 номерлы;

2013 елның 26 августындагы 277 номерлы Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы боерыгы белән расланган «Кара металл һәм төсле металл калдыкларын әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату эшчәнлеген лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең Административ регламентына үзгәрешләр кертү турында» 2016 елның 02 июнендәге 176 номерлы;

2013 елның 26 августындагы 277 номерлы Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы боерыгы белән расланган «Кара металл һәм төсле металл калдыкларын әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату эшчәнлеген лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең Административ регламентына үзгәрешләр кертү турында» 2017 елның 02 июнендәге 172 номерлы;

2013 елның 26 августындагы 277 номерлы Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы боерыгы белән расланган «Кара металл һәм төсле металл калдыкларын әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату эшчәнлеген лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең Административ регламентына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 19 апрелендәге 172 номерлы;

2013 елның 26 августындагы 277 номерлы Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы боерыгы белән расланган «Кара металл һәм төсле металл калдыкларын әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату эшчәнлеген лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең Административ регламентына үзгәрешләр кертү турында» 2018 елның 13 июлендәге 335 номерлы;

2013 елның 26 августындагы 277 номерлы Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы боерыгы белән расланган «Кара металл һәм төсле металл калдыкларын әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату эшчәнлеген лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең Административ регламентына үзгәрешләр кертү турында» 2019 елның 29 октябрендәге 545 номерлы;

2013 елның 26 августындагы 277 номерлы Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы боерыгы белән расланган «Кара металл һәм төсле металл калдыкларын әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату эшчәнлеген лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең Административ регламентына үзгәрешләр кертү турында» 2020 елның 09 сентябрендәге 405 номерлы;

2013 елның 26 августындагы 277 номерлы Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы боерыгы белән расланган «Кара металл һәм төсле металл калдыкларын әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату эшчәнлеген лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең Административ регламентына үзгәреш кертү турында» 2021 елның 05 февралендәге 42 номерлы;

2013 елның 26 августындагы 277 номерлы Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы боерыгы белән расланган «Кара металл һәм төсле металл калдыкларын әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату эшчәнлеген лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең Административ регламентына үзгәреш кертү турында» 2021 елның 03 августындагы 295 номерлы;

3. Әлеге Боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны министр урынбасары Н.В.Кондратовка йөкләргә.

**Татарстан Республикасы Премьер-министры урынбасары – министр** **М.Р. Шаһиәхмәтов**

Татарстан Республикасы
Икътисад министрлыгының 2022
елның 13 апрелендәге 138
номерлы боерыгы белән
расланды

# Кара һәм төсле металл калдыкларын әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату эшчәнлеген лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең кушымта итеп бирелгән Административ регламенты

## 1. Гомуми нигезләмәләр

1.1. Кара һәм төсле металл калдыкларын әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату эшчәнлеген лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең кушымта итеп бирелгән Административ регламенты (алга таба – Регламент) кара һәм төсле металл калдыкларын әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату эшчәнлеген лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең (алга таба – дәүләт хезмәте) стандартын һәм тәртибен билгели

1.2. Гариза бирүче булып юридик затлар һәм шәхси эшкуарлар (алга таба – лицензиягә дәгъва кылучы, лицензиат), гражданнар тора.

1.3. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә (хезмәт күрсәтүче орган тарафыннан үткәрелә торган анкета нәтиҗәсендә билгеләнгән гариза бирүченең билгеләренә туры килә торган дәүләт хезмәте күрсәтү варианты нигезендә гариза бирүчегә дәүләт хезмәте күрсәтү) профильләштерү үткәрелми.

## 2. Дәүләт хезмәте күрсәтү стандарты

### 2.1. Дәүләт хезмәте атамасы

Кара металл һәм төсле металл калдыкларын әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату эшчәнлеген лицензияләү.

### 2.2. Дәүләт хезмәте күрсәтүче орган исеме

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы (алга таба – Министрлык).

Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәге аша (алга таба – КФҮ) дәүләт хезмәте дәүләт хезмәтеннән файдалану алу өчен гариза бирү һәм хезмәт нәтиҗәсен бирү өлешендә гариза бирүченең КФҮгә дәүләт хезмәте сорап мөрәҗәгать иткәндә күрсәтелә.

КФҮнең соратуны һәм дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны һәм (яки) мәгълүматны алудан баш тарту турында карар кабул итү мөмкинлеге каралмаган.

### 2.3. Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе

Дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре:

лицензия бирү турында (лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында) лицензиатка җибәрелгән (бирелгән) хәбәрнамә (Регламентка 8 нче кушымта);

лицензиатка җибәрелгән (бирелгән) лицензиянең гамәлдә булуын туктату турында хәбәрнамә (Регламентка 10 нчы кушымта);

лицензиягә дәгъва кылучыга (лицензиатка) җибәрелгән лицензия бирүдән (лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертүдән) баш тарту турында хәбәрнамә (Регламентка 9 нчы кушымта).

Кара металл һәм төсле металл калдыкларын әзерләүгә, саклауга, эшкәртүгә һәм сатуга лицензияләр реестрында (алга таба – лицензияләр реестры) язма.

Лицензияләр реестрыннан өземтә, яисә кабул ителгән карар турында Министрлык актының күчермәсе, яисә соратып алына торган белешмәләрнең булмавы турында лицензияләр реестрында лицензияләр турында мәгълүмат булмаган яки конкрет лицензиатны билгеләү мөмкин булмаган очракта бирелә торган белешмә.

Гариза бирүче дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсен түбәндәге ысуллар белән ала:

Министрлыкка шәхсән килеп;

тапшыру турында хәбәрнамә белән заказлы почта аша;

лицензияләүче органның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ рәвешендә, «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрен дә кертеп, гомуми файдаланудагы мәгълүмат-телекоммуникация челтәрләре аша (алга таба – «Интернет» челтәре), шул исәптән Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләрнең (функцияләрнең) бердәм порталы аша (https://www.gosuslugi.ru/ (алга таба – Бердәм портал).

## 2.4. Дәүләт хезмәте күрсәтү вакыты

Лицензияне бирү лицензия бирү турында тиешенчә рәсмиләштерелгән гариза һәм аңа тулы күләмдә кушып бирелә торган документларны теркәгәннән соң 10 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү юридик зат яисә шәхси эшкуар тарафыннан лицензияләнә торган эшчәнлек төрен гамәлгә ашыру адреслары, эшчәнлекнең лицензияләнә торган төрен тәшкил итүче башкарыла торган эшләр исемле үзгәргән очракта лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында тиешенчә рәсмиләштерелгән гариза һәм аңа теркәлә торган тулы күләмдә документлар теркәлгән көннән алып 10 эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү үзгәртеп кору, кушылу, лицензиатны башка юридик затка кушу формасында юридик затны яңадан оештырганда, аның исеме, урнашкан урыны үзгәргән, шәхси эшмәкәрнең яшәү урыны, исеме, фамилиясе һәм әтисенең исеме (булган очракта), шәхесен раслый торган документ реквизитлары үзгәргән очракта, лицензияләнгән эшчәнлек төрен алып баруның аерым адреслары буенча эшчәнлек туктатылганда, лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында тиешенчә рәсмиләштерелгән гариза һәм аңа

теркәлә торган тулы күләмдә документлар теркәлгән көннән алып дүрт эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Лицензиянең гамәлдә булуын туктату лицензиатның лицензиянең гамәлдә булуын туктату турындагы гаризасын теркәгәннән соң биш эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Лицензияләр реестрыннан белешмәләр бирү лицензияләр реестрыннан белешмәләр бирү турындагы гаризаны теркәгәннән соң өч эш көне эчендә башкарыла.

Лицензияләр реестры Министрлыкның рәсми сайтында ачык рәвештә урнаштырылган.

Гариза бирүче КФҮ гә мөрәҗәгать иткәндә, гаризаны һәм кушып бирелә торган документларны Министрлыкка тапшыру Министрлык белән КФҮ арасында үзара хезмәттәшлек турында килешүдә билгеләнгән тәртиптә һәм срокларда тәэмин ителә. Дәүләт хезмәтен күрсәтү вакытына гаризаның КФҮ дә булу вакыты һәм дәүләт хезмәтенең нәтиҗәсен Министрлыктан КФҮ гә тапшыру вакыты кертелми.

Дәүләт хезмәте нәтиҗәсе булган документны бирү гариза бирүче мөрәҗәгаь иткән көндә гамәлгә ашырыла.

Дәүләт хезмәте нәтиҗәсе булган документны гаризада күрсәтелгән элемтә ысулын кулланып (почта аша яки Бердәм порталда электрон кабинетка) җибәрү дәүләт хезмәте нәтиҗәсен рәсмиләштерү һәм теркәү көнендә гамәлгә ашырыла.

2.5. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен хокукый нигезләр

Бердәм порталда, Татарстан Республикасы дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү порталында түбәндәгеләр урнаштырылган:

дәүләт хезмәте күрсәтүне җайга сала торган норматив хокукый актлар исемлеге;

дәүләт хезмәте күрсәтүне тикшереп тору өчен җаваплы органнар (учреждениеләр) һәм вазыйфаи затлар турында белешмәләр;

дәүләт хезмәтләре күрсәтүче органнарның, шулай ук аларның вазыйфаи затларының, дәүләт яки муниципаль хезмәткәрләрнең, эшчеләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) судка кадәр (судтан тыш) шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат.

2.6. Дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларның тулы исемлеге

2.6.1. Гариза бирүче шәхсән үзе тапшыра торган дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документлар:

1. Лицензия алу өчен:

а) лицензия бирү турында гариза (Регламентка 1 нче кушымта);

б) лицензиягә дәгъва кылучының лицензияләнгән эшчәнлек алып бару өчен кирәкле документларының булуын һәм аның Күчемсез мөлкәтнең бердәм дәүләт реестрында аларга хокуклар теркәлмәгән, милекчелек хокукында яисә башка законлы нигездә җир кишәрлекләре, биналар, төзелмәләр, корылмалар һәм помещениеләре (биналарның, төзелмәләрнең, корылмаларның һәм

помещениеләрнең бердәм аерымланган өлеше) булуны раслый торган күчермәләре (күрсәтелгән реестрда мондый хокуклар теркәлгән очракта, әлеге җир кишәрлекләре, биналар, төзелмәләр, корылмалар һәм помещениеләр турында белешмәләр бирелә);

в) лицензиягә дәгъва кылучының лицензияле эшчәнлекне гамәлгә ашыру өчен файдаланыла торган милек хокукында яисә башка законлы нигездә техник чаралары, җиһазлары һәм техник документлары булуын раслый торган документлар күчермәләре;

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2001 елның 11 маендагы 369 номерлы карары белән расланган Кара металл ватыклары һәм калдыклары белән эш итү һәм аларны читләштерү кагыйдәләре (алга таба – Кара металл ватыгы белән эш итү кагыйдәләре) таләпләре һәм Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2001 елның 11 маендагы 370 номерлы карары белән расланган Төсле металл ватыклары һәм калдыклары белән эш итү һәм аларны читләштерү кагыйдәләре (алга таба – Төсле металл ватыгы белән эш итү кагыйдәләре) таләпләренигезендә лицензиягә дәгъва кылучы белән хезмәт шартнамәләре төзегән хезмәткәрләрнең квалификациясен раслый торган документларның күчермәләре;

д) Кара металл ватыклары белән эш итү кагыйдәләре һәм Төсле металл ватыклары белән эш итү кагыйдәләре таләпләре нигезендә, лицензиягә дәгъва кылучының җитәкчесе тарафыннан расланган металл ватыкларына һәм калдыкларына радиация контролен үткәрү өчен, шартлау куркынычсызлыгына ватыкларны һәм калдыкларны контрольдә тоту өчен җаваплы затларны билгеләү турында документлар күчермәләре;

е) теркәлә торган документлар исемлеге.

2. Лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү өчен (юридик зат яисә шәхси эшмәкәр тарафыннан лицензияләнә торган эшчәнлек төрен гамәлгә ашыру урыннары адреслары, лицензияләнә торган эшчәнлек төрен тәшкил итүче башкарыла торган эшләр исемлеге үзгәргән очракларда):

а) лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында гариза (Регламентка 2 нче кушымта);

б) 1 пунктның б», «в», «г», «д» пунктчаларында күрсәтелгән белешмәләр булган документларның күчермәләре;

в) теркәлә торган документлар исемлеге.

3. Лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү өчен (лицензияләнә торган эшчәнлек төрен гамәлгә ашыру урыннарының аерым адреслары буенча эшчәнлек туктатылган очракта):

лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында гариза (Регламентка 2 нче кушымта).

Үзгәртеп кору, кушылу, лицензиатны башка юридик затка кушу формасында юридик затны яңадан оештырганда, аның исеме, урнашкан урыны үзгәргән, шәхси эшмәкәрнең яшәү урыны, исеме, фамилиясе һәм әтисенең исеме (булган очракта), шәхесен раслый торган документ реквизитлары үзгәргән очракта, Министрлык лицензияләр реестрына дәүләт мәгълүмат системаларыннан алынган мәгълүмат нигезендә, лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында Министрлыкка бирелгән гаризадан башка, автомат режимда кертә.

Министрлык лицензияләр реестрына дәүләт мәгълүмат системаларыннан алынган мәгълүмат нигезендә автомат режимда лицензияләрреестрына күрсәтелгән белешмәләр кертмәгән очракта, әлеге белешмәләр лицензияләр реестрына Министрлыкка лицензиат (аның хокук варисы яисә федераль законда каралган башка зат) тарафыннан бирелгән лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында гариза нигезендә Министрлыкның вәкаләтле вазыйфаи заты тарафыннан кертелә.

лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында гариза (Регламентка 2 нче кушымта).

Лицензиатның телефон номерын, электрон почта адресын үзгәртү турында белешмәләр лицензиатлар тарафыннан лицензияләр реестрына Россия Федерациясе Хөкүмәте тарафыннан расланган лицензияләр реестрын формалаштыру һәм алып бару тәртибе нигезендә мөстәкыйль рәвештә кертелә. Лицензияләр реестрына кертелә торган лицензиатның телефон номерын, электрон почта адресын үзгәртү турындагы белешмәләрнең дөреслеген тикшерү лицензияләүче орган тарафыннан үткәрелми.

Юридик затның урнашу урыны, шәхси эшкуарның яшәү урыны, географик объект, урам, мәйдан яки башка территория исемен үзгәртү, адресация объектының номерын, шул исәптән почта индексын үзгәртү белән бәйле рәвештә лицензияләнә торган эшчәнлек төрен гамәлгә ашыру урыны үзгәргән очракта, шулай ук юридик затның исемен үзгәртү, үзгәртеп кору, кушылу, кушу формасында юридик затны яңадан оештырганда, лицензия бирелгән затның гаризасы нигезендә лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү таләп ителми (2022 елда гамәлдә була).

5. Лицензиянең гамәлдә булуын туктату өчен:

лицензиатның лицензиянең гамәлдә булуын туктату турында гаризасы (Регламентка 3 нче кушымта).

6. Лицензияләр реестрыннан белешмәләр бирү өчен:

лицензияләр реестрыннан белешмәләр бирү турында гариза (Регламентка 4 нче кушымта).

Дәүләт хезмәтен алу өчен гариза бланкын гариза бирүче Министрлыкка шәхсән мөрәҗәгать иткәндә алырга мөмкин. Бланкның электрон формасы Министрлыкның рәсми сайтында урнаштырылган.

Гариза һәм аңа теркәп бирелә торган документлар гариза бирүче тарафыннан түбәндәге ысулларның берсен кулланып тапшырылырга (җибәрелергә) мөмкин:

1) Министрлыкка шәхсән яисә заказлы почта аша тапшыру турында хәбәрнамә белән мөрәҗәгать итәргә.

2) КФҮ аша кәгазьдә.

Гариза биргәндә гариза бирүчегә КФҮ дән гаризаның кабул ителүен раслый торган теркәү номеры булган расписка бирелә;

3) Бердәм портал аша.

Гаризаны Бердәм порталаша җибәргәндә, гариза бирүче гариза биргән көнне Бердәм порталдагы шәхси кабинетында гаризаның кабул ителүен раслый торган теркәү номеры белән электрон гариза бирү датасы күрсәтелгән хәбәрнамә ала.

Гариза бирүче лицензия бирү турында гаризаны һәм аңа кушып бирелә торган документларны электрон документлар (электрон документлар пакеты) рәвешендә

дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә җибәрә.

Гариза бирүчене идентификацияләү һәм аутентификацияләү «Электрон формада дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтү өчен файдаланыла торган мәгълүмат системаларының мәгълүмати-технологик хезмәттәшлеген тәэмин итә торган инфраструктурада идентификацияләү һәм аутентификацияләүнең бердәм системасы» (алга таба – идентификация һәм аутентификацияләүнең бердәм системасы) федераль дәүләт мәгълүмат системасын кулланып гамәлгә ашырыла.

Гаризаны Бердәм портал аша тапшырганда, гариза бирүче «Электрон имза турында» 2011 елның 6 апрелендәге 63-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 63-ФЗ номерлы федераль закон) таләпләренә туры китереп, мондый документларны төзүгә һәм имзалауга вәкаләтле затлар тарафыннан электрон имза белән имзаланган документларны электрон формада тапшыра.

Гариза бирүчеләр, лицензия бирү, лицензия не гамәлдән чыгару, лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында гариза һәм кирәкле документаларны Бердәм портал аша җибәргәндә, гаризаны көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзалыйлар.

Гариза бирүчеләр, лицензияләр реестрыннан белешмәләр бирү турында гаризаны Бердәм портал аша җибәргәндә, гади электрон имза белән имзалыйлар.

Гади электрон имза алу өчен, гариза бирүчегә ЕСИАда теркәлү (аутентификация) процедурасын узарга, шулай ук исәпкә алу язмасын расларга кирәк.

Гаризага теркәлеп бирелә торган электрон документлар (электрон документлар образлары), шул исәптән ышанычнамәләр pdf, jpg, jpeg, png, tif, doc, docx, rtf, sig форматларында 50 Мбайттан да артмаган күләмдә файллар рәвешендә җибәрелә.

Тапшырыла торган электрон документларның (электрон документларның образларының) сыйфаты документ текстын тулы күләмдә укырга һәм документның реквизитларын танырга мөмкинлек бирергә тиеш.

2.6.2. Ведомствоара мәгълүмати хезмәттәшлек кысаларында тапшырылырга тиешле документлар:

лицензиягә дәгъва кылучының (лицензиатның) милекчелек хокукында яисә башка законлы нигездә җир кишәрлекләре, биналар, корылмалары булуны раслый торган белешмәләр (Федераль дәүләт теркәве, кадастр һәм картография хезмәтенең Татарстан Республикасы идарәсендә);

б) Юридик затларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә (Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсендә);

в) Шәхси эшкуарларның бердәм дәүләт реестрыннан өземтә (Татарстан Республикасы буенча Федераль салым хезмәте идарәсендә).

Гариза бирүче югарыда күрсәтелгән белешмәләрне раслый торган документларны үз инициативасы буенча тапшырырга хокуклы.

2.7. Дәүләт хезмәт күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза билгеләнгән таләпләрне бозып рәсмиләштерелгән;

2) Регламентның 2.6.1 пунктчасында күрсәтелгән документларны тулы булмаган комплект белән тапшыру;

3) дәүләт хезмәтен алу хокукына ия булмаган зат мөрәҗәгате;

4) дәүләт хезмәте күрсәткән өчен дәүләт пошлинасын түләмәү (гаризалар буенча лицензия биргән, лицензияләр реестрына үзгәрешләр керткән өчен дәүләт хезмәтләре күрсәтү кысаларында 2022 елның 14 мартыннан 2022 елның 31 декабренә кадәр бирелгән дәүләт пошлиналары түләү таләп ителми);

5) электрон гариза һәм башка документлар, электрон имзаны кулланып, 63-ФЗ номерлы Федераль закон таләпләрен бозып имзаланган.

### 2.8. Дәүләт хезмәт күрсәтүне туктатып тору яки муниципаль хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләрнең тулы исемлеге.

Дәүләт хезмәт күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр юк.

Дәүләт хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр:

лицензия бирү өлешендә:

тапшырылган лицензия бирү турында гаризада һәм (яки) аңа кушып бирелә торган документларда дөрес булмаган яки ялган мәгълүмат булуы;

лицензиягә дәгъва кылучының бәяләү барышында ачыкланган лицензия таләпләренә туры килмәве;

лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү өлешендә:

тапшырылган лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында гаризада һәм (яки) аңа кушып бирелә торган документларда дөрес булмаган яки ялган мәгълүмат булуы;

лицензиатның бәяләү барышында ачыкланган лицензия таләпләренә туры килмәве;

Лицензиянең гамәлдә булуын туктату, лицензияләр реестрыннан белешмәләр бирү өлешендә дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр юк.

## 2.9. Дәүләт хезмәте күрсәткәндә гариза бирүчедән алына торган түләү күләме һәм аны алу ысуллары

Дәүләт хезмәте түләүле нигездә күрсәтелә.

Дәүләт пошлинасы:

лицензия бирү – 7 500 сум;

лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү яки лицензияне яңадан рәсмиләштерү, лицензияләнә торган эшчәнлек төрен гамәлгә ашыру урыннары адреслары, лицензияләнә торган эшчәнлек төре составында башкарыла торган эшләр турында белешмәләргә өстәмәләр кертү белән бәйле гариза нигезендә лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү яки лицензияне яңадан рәсмиләштерү – 3 500 сум;

лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында гариза нигезендә лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү яки башка очракларда лицензияне яңадан рәсмиләштерү – 750 сум.

Лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында гариза нигезендә дәүләт пошлинасын түләүне таләп итә торган бер нигездән артыграк лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертелгән яки лицензияне яңадан рәсмиләштергән очракта, зурлыгы ягыннан иң зур дәүләт пошлинасы түләнә.

Дәүләт пошлинасын түләү реквизитлары:

РОССИЯ БАНКЫ ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МБ-БҮЛЕГЕ//Татарстан Республикасы буенча Федераль казначылык идарәсе Казан шәһәре

БИК 019205400

казначылык счетының номеры 03100643000000011100

р/с 40102810445370000079

алучы:

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгы (Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы л/с 04112001020)

ИНН 1655141501

КПП 165501001

ОГРН 1071690045129

ОКПО 82318720

ОКВЭД 84.11.21

ОКТМО 92701000

Түләү идентификаторы КБК 70210807082011000110

Түләнгән дәүләт пошлинасы дәүләт пошлинасын түләгән затларның әлеге юридик әһәмияткә ия гамәлне башкаручы вәкаләтле органга (вазыйфаи затка) мөрәҗәгать итүгә кадәр юридик әһәмияткә ия гамәл кылудан баш тартуы очрагында өлешчә яисә тулысынча кире кайтарылырга тиеш.

Гаризалар буенча лицензия биргән, лицензияләр реестрына үзгәрешләр керткән өчен дәүләт хезмәтләре күрсәтү кысаларында 2022 елның 14 мартыннан 2022 елның 31 декабренә кадәр бирелгән дәүләт пошлиналары түләү таләп ителми.

Министрлык һәм (яки) вазыйфаи зат, КФҮ һәм (яки) КФҮ хезмәткәре гаебе белән кертелгән хаталарны төзәтүгә юнәлдерелгән дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча бирелгән документка үзгәрешләр кертелгән очракта, гариза

бирүчедән түләү алынмый.

## 2.10. Гариза бирүче тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы сорату биргәндә һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь вакыты

Дәүләт хезмәте күрсәтү турындагы сорату биргәндә һәм дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсен алганда чиратта көтүнең максималь вакыты 15 минуттан артмаска тиеш. Аерым категория гариза бирүчеләр өчен чират билгеләнмәгән.

## 2.11. Дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза бирүченең соратуын теркәү вакыты

Гариза бирүче гариза кергән көнне теркәлә.

Гариза бирүче яисә аның вәкиле тарафыннан КФҮ аша бирелгән гариза, КФҮ дән кергән көнне, Министрлык тарафыннан билгеләнгән тәртиптә теркәлә.

Бердәм порталга электрон рәвештә кергән гариза кергән көнендә теркәлә.

Ял (бәйрәм) көнендә эш вакытыннан тыш электрон формада кергән гариза икенче эш көненә теркәлә.

## 2.12. Дәүләт хезмәтләре күрсәтелә торган биналарга карата таләпләр

Дәүләт хезмәтен күрсәтү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы, һаваны кондиционирлау системасы, документларны рәсмиләштерү өчен кирәкле мебель, мәгълүмат стендлары белән җиһазландырылган биналарда һәм помещениеләрдә башкарыла.

Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында визуаль, текстлы һәм мультимедиа мәгълүматы гариза бирүчеләр өчен уңайлы урыннарда, шул исәптән инвалидларның чикләнгән мөмкинлекләрен исәпкә алып урнаштырыла.

Катнашу урыны Татарстан Республикасы Телекоммуникацияләренең дәүләт интеграцияләнгән системасына тоташтырылган электрон мәгълүмати киоск (инфомат) белән җиһазландырылган.

Инвалидларга, шул исәптән кресло-коляска һәм озатып йөртүче этләрдән файдаланучыларга, бинадан, помещениедән һәм хезмәт күрсәтүләрдән файдалану мөмкинлеген тәэмин итү буенча чаралар гамәлгә ашырыла:

биналарга һәм помещениеләргә, шулай ук аларга күрсәтелә торган хезмәтләргә каршылыксыз керү шартлары;

Министрлык территориясе буенча мөстәкыйль хәрәкәт итү, Министрлык бинасына һәм помещениегә керү һәм чыгу, транспорт чарасына, шул исәптән кресло-коляска кулланып утырту һәм аннан төшерү мөмкинлеге;

күрү сәләте һәм мөстәкыйль хәрәкәт итү функциясе бозылган инвалидларны бинада һәм бүлмәләрдә озатып бару һәм аларга ярдәм күрсәтү;

инвалидларның хезмәт күрсәтү урыннарына тоткарлыксыз керүен тәэмин итү өчен, кирәкле җиһазларны һәм мәгълүмат йөртү чыганакларын, аларның тормыш эшчәнлеген чикләүне исәпкә алып, бинада һәм бүлмәләрдә тиешенчә урнаштыру;

инвалидлар өчен кирәкле тавыш белән һәм күреп кабул ителә торган мәгълүматны, шулай ук язуларны, билгеләрне һәм башка текстлы һәм график

мәгълүматны Брайль рельефлы-нокталы шрифты белән башкарылган билгеләр белән кабатлау, сурдотәрҗемәчене һәм тифлосурдотәрҗемне кертү

йөртүче этне махсус укытуны раслый торган һәм «Йөртүче этне махсус укытуны раслый торган документ формасын һәм аны бирү тәртибен раслау турында» Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының 2015 елның 22 июнендәге 386н номерлы боерыгы белән расланган рәвештә һәм тәртиптә тапшырыла торган документы булганда бинага һәм помещениегә кертергә рөхсәт итү;

хезмәт күрсәтүче хезмәткәрләр тарафыннан инвалидларга башкалар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләрдән файдаланырга комачаулаучы каршылыкларны узуда ярдәм итү.

Дәүләт хезмәт күрсәтү гамәлгә ашырыла торган объектлардан инвалидларның файдалана алуын тәэмин итү өлешендә таләпләр 2016 елның 1 июленнән соң файдалануга тапшырылган, капиталь ремонт, реконструкция үткән, яңартылган объектларга карата кулланыла.

### 2.13. Дәүләт хезмәтенең үтемлелеге һәм сыйфаты күрсәткечләре

Дәүләт хезмәт күрсәтүнең сыйфат күрсәткечләренә түбәндәгеләр керә:

документларны кабул итү һәм карау сроклары үтәлү;

дәүләт хезмәт күрсәтү нәтиҗәсен алу срогы үтәлү;

Дәүләт хезмәткәрләре тарафыннан Регламентны бозуга карата нигезле шикаятьләр булмау;

Дәүләт хезмәт күрсәтүнең үтемлелеге күрсәткечләренә түбәндәгеләр керә:

Министрлык биналарының җәмәгать транспортыннан файдалану мөмкин булган зонада урнашуы;

белгечләрнең, шулай ук гариза бирүчеләрдән документлар кабул итә торган бүлмәләрнең җитәрлек санда булуы;

мәгълүмат стендларында, «Интернет» челтәрендә, Министрлыкның рәсми сайтында дәүләт хезмәте күрсәтүнең ысуллары, тәртибе, сроклары турында тулы мәгълүмат булу;

гаризаны электрон рәвештә бирү мөмкинлеге;

инвалидларга башкалар белән тигез дәрәҗәдә хезмәтләрдән файдаланырга комачаулаучы каршылыкларны узуда ярдәм итү;

дәүләт хезмәте күрсәтелә торган бүлмәләрнең инвалидлар өчен уңайлы булуы, инвалидларга башка затлар белән бертигез дәрәҗәдә хезмәт алырга комачаулый торган, инвалидлар өчен биналардан файдалану уңайлылыгын тәэмин итүгә бәйле булмаган башка каршылыкларны җиңеп чыгуда ярдәм күрсәтү;

гариза бирүченең, Бердәм портал аша электрон документлар формасында гариза һәм документлар биргәндә, хезмәт күрсәтү нәтиҗәләрен Бердәм порталда шәхси кабинет аша электрон рәвештә алу мөмкинлеге.

КФҮ дә дәүләт хезмәте күрсәткәндә консультация бирүне, документларны кабул итүне һәм тапшыруны КФҮ белгече башкара.

Дәүләт хезмәтен күрсәткәндә Министрлык һәм МФЦ арасындагы хезмәттәшлек тәртибе – Министрлык һәм КФҮ арасында төзелә торган

хезмәттәшлек турындагы килешү белән, ә КФҮ нең гариза бирүчеләр белән хезмәттәшлеге тәртибе КФҮ нең эше регламенты белән җайга салына.

Дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүматны гариза бирүче Министрлыкта, Бердәм порталда шәхси кабинетында, КФҮ дә алырга мөмкин.

## 2.14. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә башка таләпләр

Кирәкле һәм мәҗбүри хезмәтләр күрсәтү таләп ителми.

Дәүләт хезмәте күрсәткәндә түбәндәгеләр кулланыла:

«Ведомствоара электрон хезмәттәшлекнең бердәм системасы» федераль дәүләт мәгълүмат системасы;

«Контроль (күзәтчелек) эшчәнлеген автоматлаштыру буенча типлаштырылган болытлы карар» дәүләт мәгълүмат системасы.

Дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында мәгълүмат Татарстан Республикасы дәүләт телләрендә урнаштырыла.

# 3. Административ процедураларның составы, эзлеклелеге һәм сроклары

## 3.1. Дәүләт хезмәте күрсәтүдәге гамәлләр тәртибен тасвирлау

Кара һәм төсле металл калдыкларын әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату эшчәнлеген лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтү үз эченә түбәндәгеләрне ала:

1) лицензиягә дәгъва кылучыга, лицензиатка консультация бирү, гариза бирүчегә ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү буенча;

2) лицензия бирү:

а) КФҮдән, Бердәм порталдан, Министрлыкка язмача мөрәҗәгать иткәндә алынган гаризаны кабул итү һәм теркәү;

б) лицензия таләпләрен үтәүне күчмә бәяләү уздыру;

б) дәүләт хезмәте нәтиҗәләрен әзерләү;

в) лицензиягә дәгъва кылучыга дәүләт хезмәте нәтиҗәсен бирү;

3) лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү (юридик зат яисә шәхси эшмәкәр тарафыннан лицензияләнә торган эшчәнлек төрен гамәлгә ашыру урыннары адреслары, лицензияләнә торган эшчәнлек төрен тәшкил итүче башкарыла торган эшләр исемлеге үзгәргән очракларда):

а) КФҮдән, Бердәм порталдан, Министрлыкка язмача мөрәҗәгать иткәндә алынган гаризаны кабул итү һәм теркәү;

б) лицензия таләпләрен үтәүне күчмә бәяләү уздыру;

б) дәүләт хезмәте нәтиҗәләрен әзерләү;

в) лицензиатка дәүләт хезмәте нәтиҗәсен бирү;

4) Лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү (үзгәртеп кору, кушылу, лицензиатны башка юридик затка кушу формасында юридик затны яңадан оештырганда, аның исеме, урнашкан урыны үзгәргән, шәхси эшмәкәрнең яшәү урыны, исеме, фамилиясе һәм әтисенең исеме (булган очракта), шәхесен раслый

торган документ реквизитлары үзгәргән очракта, лицензияләнгән эшчәнлек төрен алып баруның аерым адреслары буенча эшчәнлек туктатылган очракларда):

а) КФҮдән, Бердәм порталдан, Министрлыкка язмача мөрәҗәгать иткәндә алынган гаризаны кабул итү һәм теркәү;

б) дәүләт хезмәте нәтиҗәләрен әзерләү;

в) лицензиатка дәүләт хезмәте нәтиҗәсен бирү;

5) лицензиянең гамәлдә булуын туктату:

а) КФҮдән, Бердәм порталдан, Министрлыкка язмача мөрәҗәгать иткәндә алынган гаризаны кабул итү һәм теркәү;

б) дәүләт хезмәте нәтиҗәләрен әзерләү;

в) лицензиатка дәүләт хезмәте нәтиҗәсен бирү;

6) лицензияләр реестрыннан белешмәләр бирү:

а) КФҮдән, Бердәм порталдан, Министрлыкка язмача мөрәҗәгать иткәндә алынган гаризаны кабул итү һәм теркәү;

б) дәүләт хезмәте нәтиҗәләрен әзерләү;

в) лицензиатка дәүләт хезмәте нәтиҗәсен бирү;

7) техник хаталарны төзәтү.

3.2. Лицензия алырга теләүчегә, лицензиатка консультация бирү, мөрәҗәгать итүчегә ярдәм күрсәтү, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү буенча.

Лицензиягә дәгъва кылучы, лицензиат, дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе һәм вакыты турында консультация сорап, КФҮ гә шәхсән яки телефон аша мөрәҗәгать итәргә хокуклы.

КФҮ хезмәткәре лицензиягә дәгъва кылучыга, шул исәптән дәүләт хезмәте алу өчен тапшырыла торган документларның составы, формасы һәм башка мәсьәләләр буенча консультация бирә.

Гариза бирүче дәүләт хезмәте күрсәтү тәртибе турында мәгълүматны күпфункцияле үзәк сайтыннан http://mfc16.tatarstan.ru ирекле рәвештә алырга мөмкин.

Лицензиягә дәгъва кылучы, лицензиат шәхсән үзе, телефон һәм (яки) электрон почта аша дәүләт хезмәтен алу тәртибе турында консультацияләр алу өчен Министрлыкның лицензияләү бүлегенә (алга таба – Бүлек) мөрәҗәгать итә.

Бүлек белгече лицензиягә дәгъва кылучыга, лицензиатка, шул исәптән составы, тапшырыла торган документлар формасы буенча консультацияләр бирә, гариза бирүчегә, шул исәптән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү өлешендә һәм дәүләт хезмәте алу өчен башка мәсьәләләр буенча ярдәм күрсәтә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар лицензиягә дәгъва кылучы, лицензиат мөрәҗәгать иткән көндә башкарыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: составы, тапшырыла торган документлар формасы һәм лицензияләү буенча башка сораулар буенча консультацияләр.

3.3. Лицензия бирү, лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү (юридик зат яисә шәхси эшмәкәр тарафыннан лицензияләнә торган эшчәнлек төрен гамәлгә ашыру урыннары адреслары, лицензияләнә торган эшчәнлек төрен тәшкил итүче башкарыла торган эшләр исемлеге үзгәргән очракларда).

3.3.1. Гариза Министрлыкка шәхсән, ышанычлы зат аша, почта аша, Бердәм портал, КФҮ аша тапшырылырга мөмкин.

Лицензиягә дәгъва кылучы, лицензиат лицензия бирү турында (лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында) гариза һәм аңа кушып бирелә торган документларны, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә, электрон документлар (электрон документлар пакеты) рәвешендә, регламентның 2.6 пунктындагы1 (2) пунктчасы нигезендә җибәрә.

Гариза һәм кушып бирелә торган документларны гариза бирүче турыдан-туры кәгазьдә тапшырырга яисә заказлы почта аша, тапшыру турында хәбәрнамә белән Министрлыкның эш башкару бүлегенә (алга таба – эш башкару бүлеге) җибәрергә хокуклы.

Гаризаны Бердәм портал аша электрон рәвештә биргән очракта, гариза бирүче түбәндәге гамәлләрне башкара:

Бердәм порталда авторизация үтә;

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле һәм мәҗбүри белешмәләрне үз эченә алган электрон гариза формасын Бердәм порталда тутыра;

электрон гариза формасына электрон формадагы документларны (кирәк булганда) беркетә;

электрон рәвештә дәүләт хезмәте күрсәтүнең шартлары һәм тәртибе белән танышу һәм килешү фактын раслый (электрон гариза формасында ризалык турында тиешле тамга куя);

хәбәр ителгән белешмәләрнең дөреслеген раслый (электрон гариза формасында тиешле тамганы билгели);

электрон гариза җибәрә (электрон гариза формасында тиешле төймәгә баса);

электрон гариза, 63-ФЗ номерлы Федераль закон, «Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль закон (алга таба – 210-ФЗ номерлы Федераль закон) таләпләренә туры китереп, гади электрон имза яисә көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзалана;

электрон гариза җибәрү турында хәбәр ала.

КФҮ, КФҮнең читтәге эш урыны аша гариза биргән очракта, КФҮ нең гариза кабул итүче белгече түбәндәгеләрне башкара:

гаризалар һәм документлар кабул итү;

гаризаны теркәү;

гариза тутыруның тулылыгын һәм дөреслеген тикшерү;

лицензгә дәгъва кылучыга, лицензиатка гариза җибәрү датасы турында хәбәр итү;

документлар пакетын формалаштыру һәм аны Министрлыкка КФҮ эше Регламентында билгеләнгән тәртиптә җибәрү.

Регламентның әлеге пункты белән билгеләнә торган процедуралар түбәндәгечә гамәлгә ашырыла: Министрлыкка, Бердәм портал аша гариза биргән очракта, гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне; КФҮ, КФҮ нең читтәге эш урыны аша гариза биргәндә, КФҮнең эш регламенты белән билгеләнгән вакытта.

Процедураларның нәтиҗәсе: Министрлыкка җибәрелгән гариза.

3.3.2. Эш башкару бүлеге белгече түбәндәгеләрне башкара:

Лицензия бирү турында (лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында) гаризаны һәм аңа кушып бирелә торган документларны исемлек нигезендә кабул итү

Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнарының электрон документлар әйләнеше бердәм ведомствоара системасында (алга таба – Электрон Хөкүмәт) лицензия бирү турында (лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында) гаризаны теркәү;

лицензиягә дәгъва кылучыга (лицензиатка) лицензия алу турында (лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында) гариза кабул итү датасы турында билге белән һәм аңа кушып бирелә торган документларның исемлеге күчермәләрен тапшыру яисә тапшыру турында хәбәрнамә белән заказлы почта аша яисә лицензиягә дәгъва кылучының (лицензиатның) сайлавы буенча лицензияләүче органның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ формасында, лицензиягә дәгъва кылучының (лицензиатның) мондый күчермәне алуын раслауны һәм күрсәтелгән документны илтеп җиткерүне раслауны тәэмин итә торган ысул белән;

лицензия бирү турында (лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында) гаризаны һәм аңа кушып бирелә торган документларны Бүлеккә тапшыру.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар лицензия бирү (лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында) гариза һәм аңа кушып бирелә торган документлар кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Бүлеккә карауга җибәрелгән лицензия бирү турында (лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында) теркәлгән гариза һәм аңа кушып бирелә торган документлар.

3.3.3. Бүлек белгече түбәндәгеләрне башкара:

лицензия эшен рәсмиләштерү;

лицензиягә дәгъва кылучы (лицензиат) турында мәгълүматны Министрлыкның рәсми сайтында урнаштыру;

Регламентка 1 нче кушымтада күрсәтелгән билгеләнгән форма нигезендә лицензия бирү турында гариза рәсмиләштерүнең (Регламентка 2 нче кушымтада күрсәтелгән билгеләнгән форма нигезендә лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында гаризаның) туры килүен тикшерү;

Регламентның 2.6 пунктындагы 1 (2) пунктчаларында күрсәтелгән документларның тапшырылган пакеты составының тулылыгын тикшерү;

дәүләт һәм муниципаль түләүләр турында Дәүләт мәгълүмат системасында дәүләт хезмәте күрсәткән өчен дәүләт пошлинасын түләүне тикшерү (гаризалар буенча лицензия биргән, лицензияләр реестрына үзгәрешләр керткән өчен дәүләт хезмәтләре күрсәтү кысаларында 2022 елның 14 мартыннан 2022 елның 31 декабренә кадәр бирелгән дәүләт пошлиналары түләү таләп ителми);

тапшырылган документларны тикшерә һәм документларны кабул итүдән баш тарту өчен Регламентның 2.7 пунктында каралган нигезләрнең булуын (булмавын) билгели.

Регламентның 2.7 пунктындагы 3, 4, 5 пунктчаларында каралган документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр ачыкланган очракта, Бүлек белгече, сәбәпләрен күрсәтеп, документларны кабул итүдән баш тарту турында хәбәрнамә әзерли (Регламентка 7 нче кушымта), лицензиягә дәгъва кылучыга (лицензиатка) тапшыра, яисә тапшыру турында хәбәрнамә белән заказлы почта аша яисә лицензиягә дәгъва кылучының (лицензиатның) сайлавы буенча лицензияләүче органның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ формасында, лицензиягә дәгъва кылучының (лицензиатның) мондый хәбәрнамәне алуын раслауны һәм аны илтеп җиткерүне раслауны тәэмин итә торган ысул белән җибәрә.

Регламентның 2.7 пунктындагы 3, 4, 5 пунктчаларында каралган документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр ачыкланган очракта, Бүлек белгече, лицензиягә дәгъва кылучыга (лицензиатка) ачыкланган хокук бозуларны утыз көн эчендә бетерү һәм (яисә) документлар тапшыру кирәклеге турында хәбәрнамә бирә (Регламентка 5 нче кушымта), яисә тапшыру турында хәбәрнамә белән заказлы почта аша яисә лицензиягә дәгъва кылучының (лицензиатның) сайлавы буенча лицензияләүче органның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ формасында, лицензиягә дәгъва кылучының (лицензиатның) мондый хәбәрнамәне алуын раслауны һәм аны илтеп җиткерүне раслауны тәэмин итә торган ысул белән җибәрә. Лицензиягә дәгъва кылучы (лицензиат) тарафыннан, хәбәрнамәне алганнан соң 30 көн эчендә лицензия бирү турында (лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында) тиешле рәвештә рәсмиләштерелгән гариза һәм (яки) аңа кушып бирелә торган тулы күләмдә документлар тапшырылмаган очракта, лицензия бирү турында (лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында) элек бирелгән гариза һәм аңа кушып бирелә торган документлар лицензиягә дәгъва кылучыга (лицензиатка) кире кайтарылырга тиеш.

Регламентның 2.7 пунктында күрсәтелгән документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булмаганда, Бүлек белгече лицензия таләпләрен үтәүне күчмә бәяләү үткәрү турында боерык проектын әзерли.

Бүлек башлыгы, юридик бүлек башлыгы лицензия таләпләре үтәлешен күчмә бәяләү үткәрү турында боерык проектын килештерәләр, ул лицензияләү мәсьәләләре белән идарә итүче министр урынбасарына (алга таба – министр урынбасары) җибәрелә.

Министр урынбасары лицензия таләпләре үтәлешен күчмә бәяләү үткәрү турында боерыкка имза сала. Бүлек белгече лицензиягә дәгъва кылучыга (лицензиатка) теләсә нинди үтемле юл белән, шул исәптән лицензиягә дәгъва кылучының (лицензиатның) электрон почта адресына көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ юлламасы аша күчмә бәяләү үткәрү турында аны үткәрү башланганчы өч эш көнендә хәбәр итә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар алдагы процедураны тәмамлаганнан соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: лицензия таләпләре үтәлешен күчмә бәяләүне үткәрү турында боерык, лицензия таләпләре үтәлешен күчмә бәяләүне үткәрү турында хәбәрнамә, яисә ачыкланган җитешсезлекләрне бетерү һәм (яки) булмаган документларны бирү зарурлыгы турында хәбәрнамә, лицензия бирү турында (лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында) бирелгән гаризаны һәм аңа кушып бирелгән документларны кире кайтару турында хәбәрнамә (Регламентка 6 нчы кушымта), документларны кабул итүдән баш тарту турында хәбәрнамә.

Дәүләт хезмәте күрсәтү вакытын, ягъни лицензия бирү (лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында) яки аны бирүдән (лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертүдән) баш тарту турында карар кабул итү вакытын исәпләү, Министрлыкка лицензия бирү турында (лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында) тиешенчә рәсмиләштерелгән гариза һәм аңа кушып бирелә торган тулы күләмдә документлар кергән көннән исәпләнелә.

3.3.4. Бүлек белгече электрон формада ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша соратулар җибәрә:

юридик затларның Бердәм дәүләт реестрыннан яисә шәхси эшкуарларның Бердәм дәүләт реестрыннан өземтә бирү турында– Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә;

лицензиягә дәгъва кылучының (лицензиатның) милекчелек хокукында яисә башка законлы нигездә җир кишәрлекләре, биналар, корылмалары булуны раслый торган белешмәләрне тапшыру турында, – Федераль дәүләт теркәве, кадастр һәм картография хезмәтенең Татарстан Республикасы идарәсенә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар Регламентның 3.3.2 пунктында каралган процедураны тәмамлаган көннән соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: мәгълүмат бирү турында соратулар.

3.3.5. Ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша килгән мөрәҗәгатьләр нигезендә мәгълүмат белән тәэмин итүче белгечләр дәүләт хезмәте күрсәтү өчен сорала торган документларны (мәгълүматны) бирә яисә кирәкле документлар һәм (яисә) мәгълүмат булмау турында хәбәрнамә (алга таба – баш тарту турында хәбәрнамә) җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар законнарда билгеләнгән срокларда җибәрелгән соратулар нигезендә мәгълүмат белән тәэмин итүче тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Бүлеккә җибәрелгән документлар (белешмәләр) яки баш тарту турында хәбәрнамә.

3.3.6. Бүлек белгече (белгечләре) лицензияләнә торган эшчәнлек төрен гамәлгә ашыру өчен игълан ителгән урында лицензия таләпләре үтәлешенә күчмә бәя бирә (үткәрә).

Лицензия таләпләре үтәлешен күчмә бәяләү нәтиҗәләре буенча ике нөсхәдә бәяләү акты рәсмиләштерелә.

Тикшерү актының беренче нөсхәсе лицензия эшенә тегеп куела. Тикшерү актының икенче нөсхәсе лицензиягә дәгъва кылучыга тапшырыла.

Әлеге пункт белән билгеләнгән процедуралар өч эш көне дәвамында гамәлгә ашырыла. Процедура Регламентның 3.3.3 пунктында каралган процедураны

тәмамлаганнан соң өч эш көненнән башлана

Процедураның нәтиҗәсе: бәяләү акты.

3.3.7. 2.8 пунктында лицензия бирү (лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү) өлешендә каралган хезмәт күрсәтүдән баш тарту өчен нигезләр ачыкланган очракта, Бүлек белгече лицензия бирүдән (лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертүдән) баш тарту турында боерык проектын әзерли һәм аны Бүлек башлыгына юридик бүлек башлыгына килештерүгә җибәрә.

Бүлек башлыгы, юридик бүлек башлыгы министр урынбасарына имзага җибәрелә торган лицензия бирүдән баш тарту турында боерык проектын килештерәләр.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар алдагы процедураны тәмамлаганнан соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: министр урынбасарына кул куюга җибәрелгән лицензия бирүдән (лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертүдән) баш тарту турында боерыкның килештерелгән проекты.

3.3.8. Министр урынбасары лицензия бирүдән (лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертүдән) баш тарту турында боерыкка имза сала.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар алдагы процедураны тәмамлаганнан соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: лицензия бирүдән (лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертүдән) баш тарту турында имзаланган боерык.

3.3.9. Бүлек белгече лицензиягә дәгъва кылучыга (лицензиатка) тапшыра яки лицензиягә дәгъва кылучыга (лицензиатка) үзенең теләге буенча тапшыру турында хәбәрнамә белән заказлы почта аша йә көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә, лицензия бирүдән (лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертүдән) баш тарту турында хәбәрнамә җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура лицензия бирүдән (лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертүдән) баш тарту турында боерыкка кул куйганнан соң өч эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: баш тарту сәбәпләрен күрсәтеп, лицензия бирүдән (лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертүдән) баш тарту турында хәбәрнамә , (Регламентка 9 нчы кушымта).

3.3.10. Лицензиягә дәгъва кылучы (лицензиат) тарафыннан лицензияләнә торган эшчәнлек төрен гамәлгә ашыру урынында лицензия таләпләрен үтәү мөмкинлеге –бәяләү актында күрсәтелә – ачыкланган очракта, Бүлек башлыгы, юридик бүлек башлыгы лицензия бирү турында (лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында) боерык проектын килештерәләр, ул министр урынбасарына имзага җибәрелә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар Регламентның 3.3.6 пунктында каралган процедураны тәмамлаган көннән соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: министр урынбасарына кул куюга җибәрелгән лицензия бирү турында (лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында) боерыкның килештерелгән проекты.

3.3.11. Министр урынбасары лицензия бирү (лицензияләр реестрына

үзгәрешләр кертү) турында боерыкка имза сала.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура алдагы процедураны тәмамлаганнан соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: лицензия бирү (лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү) турында имзаланган боерык.

3.3.12. Бүлек белгече лицензия бирү турында (лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында) имзаланган боерык нигезендә бирү турында (лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында) язма, шул исәптән бирү турында (лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында) боерык реквизитларын да кертә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура лицензия бирү (лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында) боерыкка кул куелган көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: лицензияләр реестрына кертелгән язма.

3.3.13. Бүлек белгече лицензиатка лицензия бирү турында (лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында) «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнашкан лицензияләр реестрыннан белешмәләргә сылтама булган хәбәрнамә җибәрә. Лицензия бирү турында (лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында) күрсәтелгән хәбәрнамә Министрлык тарафыннан лицензиатның лицензия бирү турында (лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында) гаризада күрсәтелгән электрон почтасына җибәрелергә мөмкин. Лицензиягә дәгъва кылучы (лицензиат) тарафыннан лицензия бирү турында (лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында) гариза һәм аңа кушып бирелә торган документлар электрон документлар (электрон документлар комплекты) рәвешендә Бердәм порталдан файдаланып бирелсә, лицензия бирү турында (лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында) лицензиягә дәгъва кылучы (лицензиатка) Бердәм порталда аның шәхси кабинетына җибәрелә. Хәбәрнамә кәгазьдә җибәрелергә мөмкин (Регламентка 8 нче кушымта).

Гариза бирүче КФҮ гә дәүләт хезмәте сорап мөрәҗәгать иткәндә, КФҮ хезмәткәре гариза бирүчегә кәгазь чыганакта дәүләт хезмәте нәтиҗәсен бирә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар мөрәҗәгать итүче килгән көнне КФҮ эшчәнлеге регламентында билгеләнгән срокларда чират тәртибендә башкарыла.

Гариза бирүче Бердәм портал аша мөрәҗәгать иткәндә, автомат рәвештә гариза бирүченең шәхси кабинетына көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган электрон документ җибәрелә.

Лицензия бирү турында (лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында) гаризада лицензиягә дәгъва кылучы (лицензиат) лицензияләр реестрыннан электрон документ формасында өземтә алу кирәклеген күрсәткән очракта, лицензияләүче орган лицензия бирү турында (лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында) хәбәрнамә җибәрү белән бер үк вакытта лицензиатка көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ формасында лицензияләр реестрыннан өземтә җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар Регламентның 3.3.11

пунктында каралган процедураны тәмамлаган көннән соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла. Лицензия бирү, лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында хәбәрнамә кәгазьдә рәсмиләштерелә икән, хәбәр итү вакыты өч эш көненә кадәр артырга мөмкин.

Процедураларның нәтиҗәсе: лицензиатка лицензия бирү, лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында хәбәрнамә, кирәк булган очракта лицензияләр реестрыннан өземтә.

3.4. Лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү (үзгәртеп кору, кушылу, лицензиатны башка юридик затка кушу формасында юридик затны яңадан оештырганда, аның исеме, урнашкан урыны үзгәргән, шәхси эшмәкәрнең яшәү урыны, исеме, фамилиясе һәм әтисенең исеме (булган очракта), шәхесен раслый торган документ реквизитлары үзгәргән очракта, лицензияләнгән эшчәнлек төрен алып баруның аерым адреслары буенча эшчәнлек туктатылган очракларда)

3.4.1. Гариза Министрлыкка шәхсән, ышанычлы зат аша, почта аша, Бердәм портал, КФҮ аша тапшырылырга мөмкин.

Гариза һәм кушып бирелә торган документларны гариза бирүче турыдан-туры кәгазьдә тапшырырга яисә заказлы почта аша, тапшыру турында хәбәрнамә белән эш башкару бүлегенә җибәрергә хокуклы.

Лицензиат лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында гариза һәм аңа кушып бирелә торган документларны, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында Россия Федерациясе законнарында билгеләнгән тәртиптә, электрон документлар (электрон документлар пакеты) рәвешендә, регламентның 2.6 пунктындагы 3 пунктчасы нигезендә җибәрә.

КФҮ, КФҮнең читтәге эш урыны аша гариза биргән очракта, КФҮ нең гариза кабул итүче белгече түбәндәгеләрне башкара:

гаризалар һәм документлар кабул итү;

гаризаны теркәү;

гариза тутыруның тулылыгын һәм дөреслеген тикшерү;

лицензиатка гариза җибәрү датасы турында хәбәр итү;

документлар пакетын формалаштыру һәм аны Министрлыкка КФҮ эше Регламентында билгеләнгән тәртиптә җибәрү.

Регламентның әлеге пункты белән билгеләнә торган процедуралар түбәндәгечә гамәлгә ашырыла: Министрлыкка, Бердәм портал аша гариза биргән очракта, гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне; КФҮ, КФҮ нең читтәге эш урыны аша гариза биргәндә, КФҮнең эш регламенты белән билгеләнгән вакытта.

Процедураларның нәтиҗәсе: Министрлыкка җибәрелгән гариза.

3.4.2. Лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында гаризаны кабул итү, теркәү һәм Бүлеккә җибәрү Регламентның 3.3.2 пункты нигезендә гамәлгә ашырыла.

3.4.3. Бүлек белгече түбәндәгеләрне башкара:

Регламентка 2 нче кушымтада күрсәтелгән билгеләнгән форма нигезендә лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында гаризаны рәсмиләштерүнең туры килүен тикшерү;

Регламентның 2.6 пунктындагы 3 пунктчасында күрсәтелгән документларның тапшырылган пакеты составының тулылыгын тикшерү;

дәүләт һәм муниципаль түләүләр турында Дәүләт мәгълүмат системасында дәүләт хезмәте күрсәткән өчен дәүләт пошлинасын түләүне тикшерү (гаризалар буенча лицензия биргән, лицензияләр реестрына үзгәрешләр керткән өчен дәүләт хезмәтләре күрсәтү кысаларында 2022 елның 14 мартыннан 2022 елның 31 декабренә кадәр бирелгән дәүләт пошлиналары түләү таләп ителми);

тапшырылган документларны тикшерә һәм документларны кабул итүдән баш тарту өчен Регламентның 2.7 пунктында каралган нигезләрнең булуын (булмавын) билгели.

Регламентның 2.7 пунктындагы 3, 4, 5 пунктчаларында каралган документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр ачыкланган очракта, Бүлек белгече, сәбәпләрен күрсәтеп, документларны кабул итүдән баш тарту турында хәбәрнамә әзерли (Регламентка 7 нче кушымта), лицензиатка (гариза бирүчегә) тапшыра, яисә тапшыру турында хәбәрнамә белән заказлы почта аша яисә лицензиатның (гариза бирүченең) сайлавы буенча лицензияләүче органның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ формасында, лицензиатның (гариза бирүченең) мондый хәбәрнамәне алуын раслауны һәм аны илтеп җиткерүне раслауны тәэмин итә торган ысул белән җибәрә.

Регламентның 2.7 пунктындагы 1, 2 пунктчаларында каралган документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр ачыкланган очракта, Бүлек белгече лицензиатка хәбәрнамә алганнан соң 30 көн эчендә ачыкланган җитешсезлекләрне бетерү һәм (яки) булмаган документларны (регламентка 5 нче кушымта) тапшыру кирәклеге турында хәбәрнамә бирә яисә мондый белдерүне тапшыру турында хәбәрнамә белән заказлы почта аша яисә лицензияләүче органның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ рәвешендә җибәрә. Лицензиат тарафыннан, хәбәрнамәне алганнан соң 30 көн эчендә лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында тиешле рәвештә рәсмиләштерелгән гариза һәм (яки) аңа кушып бирелә торган тулы күләмдә документлар тапшырылмаган очракта, лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында элек бирелгән гариза һәм аңа кушып бирелә торган документлар лицензиатка кире кайтарылырга тиеш.

Регламентның 2.7 пунктында күрсәтелгән документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булмаганда, Бүлек башлыгы, юридик бүлек башлыгы, лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында боерык проектын килештерәләр, ул министр урынбасарына имзага җибәрелә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар Регламентның 3.4.2 пунктында каралган процедураны тәмамлаган көннән соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында боерык проекты йә ачыкланган җитешсезлекләрне бетерү һәм (яки) булмаан документларны бирү зарурлыгы турында хәбәрнамә, лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында бирелгән гаризаны һәм аңа кушып бирелә торган документларны кире кайтару турында хәбәрнамә (Регламентка 6 нчы кушымта), документларны кабул итүдән баш тарту турында хәбәрнамә.

Дәүләт хезмәте күрсәтү вакытын, ягъни лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында яки лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертүдән баш тарту турында карар кабул итү вакытын исәпләү, Министрлыкка лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында тиешенчә рәсмиләштерелгән гариза һәм аңа кушып бирелә торган тулы күләмдә документлар кергән көннән исәпләнелә.

3.4.4. Бүлек белгече электрон формада ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша соратулар җибәрә:

юридик затларның Бердәм дәүләт реестрыннан яисә шәхси эшкуарларның Бердәм дәүләт реестрыннан өземтә бирү турында– Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар Регламентның 3.4.2 пунктында каралган процедураны тәмамлаган көннән соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: мәгълүмат бирү турында соратулар.

3.4.5. Ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша килгән мөрәҗәгатьләр нигезендә мәгълүмат белән тәэмин итүче белгечләр дәүләт хезмәте күрсәтү өчен сорала торган документларны (мәгълүматны) бирә яисә кирәкле документлар һәм (яисә) мәгълүмат булмау турында хәбәрнамә (алга таба – баш тарту турында хәбәрнамә) җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар законнарда билгеләнгән срокларда җибәрелгән соратулар нигезендә мәгълүмат белән тәэмин итүче тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Бүлеккә җибәрелгән документлар (белешмәләр) яки баш тарту турында хәбәрнамә.

3.4.6. Министр урынбасары лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында боерыкка имза сала.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура алдагы процедураны тәмамлаганнан соң ике эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедуралар нәтиҗәсе: лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында имзаланган боерык.

3.4.7. Бүлек белгече лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында имзаланган боерык нигезендә лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында язма, шул исәптән лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында боерык реквизитларын да кертә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында боерыкка кул куелган көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: лицензияләр реестрына кертелгән язма.

3.4.8. Бүлек белгече лицензиатка лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында «Интернет» мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнашкан лицензияләр реестрыннан белешмәләргә сылтама булган хәбәрнамә җибәрә. Лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында күрсәтелгән хәбәрнамә Министрлык тарафыннан лицензиатның лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында гаризасында күрсәтелгән электрон почтасына җибәрелергә мөмкин. Ллицензиат тарафыннан лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында гариза һәм аңа кушып бирелә торган документлар электрон документлар (электрон

документлар комплекты) рәвешендә Бердәм порталдан файдаланып бирелсә, ллицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында лицензиатка Бердәм порталда аның шәхси кабинетына җибәрелә. Хәбәрнамә кәгазьдә җибәрелергә мөмкин (Регламентка 8 нче кушымта).

Гариза бирүче КФҮ гә дәүләт хезмәте сорап мөрәҗәгать иткәндә, КФҮ хезмәткәре гариза бирүчегә кәгазь чыганакта дәүләт хезмәте нәтиҗәсен бирә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар мөрәҗәгать итүче килгән көнне КФҮ эшчәнлеге регламентында билгеләнгән срокларда чират тәртибендә башкарыла.

Гариза бирүче Бердәм портал аша мөрәҗәгать иткәндә, автомат рәвештә гариза бирүченең шәхси кабинетына көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган электрон документ җибәрелә.

Лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында гаризада лицензиат лицензияләр реестрыннан электрон документ формасында өземтә алу кирәклеген күрсәткән очракта, лицензияләүче орган лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында хәбәрнамә җибәрү белән бер үк вакытта лицензиатка көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ формасында лицензияләр реестрыннан өземтә җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар Регламентның 3.4.6 пунктында каралган процедураны тәмамлаган көннән соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла. Лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында хәбәрнамә кәгазьдә рәсмиләштерелә икән, хәбәр итү вакыты өч эш көненә кадәр артырга мөмкин.

Процедураларның нәтиҗәсе: лицензиатка лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында хәбәрнамә, кирәк булган очракта лицензияләр реестрыннан өземтә.

### 3.5. Лицензиянең гамәлдә булуын туктату.

3.5.1. Гариза Министрлыкка шәхсән, ышанычлы зат аша, почта аша, Бердәм портал, КФҮ аша тапшырылырга мөмкин.

Лицензиат кәгазь кәгазьдә яисә заказлы почта аша тапшыру турында хәбәрнамә белән, я электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә, эш башкару бүлегенә лицензиянең гамәлдә булуын туктату турында гариза бирә (җибәрә).

КФҮ, КФҮнең читтәге эш урыны аша гариза биргән очракта, КФҮ нең гариза кабул итүче белгече түбәндәгеләрне башкара:

гаризалар һәм документлар кабул итү;

гаризаны теркәү;

гариза тутыруның тулылыгын һәм дөреслеген тикшерү;

лицензиатка гариза җибәрү датасы турында хәбәр итү;

документлар пакетын формалаштыру һәм аны Министрлыкка КФҮ эше Регламентында билгеләнгән тәртиптә җибәрү.

Регламентның әлеге пункты белән билгеләнә торган процедуралар түбәндәгечә гамәлгә ашырыла: Министрлыкка, Бердәм портал аша гариза биргән

очракта, гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне; КФҮ, КФҮ нең читтәге эш урыны аша гариза биргәндә, КФҮнең эш регламенты белән билгеләнгән вакытта.

Процедураларның нәтиҗәсе: Министрлыкка җибәрелгән гариза.

3.5.2. Эш башкару бүлеге белгече түбәндәгеләрне башкара:

лицензиянең гамәлдә булуын туктату турында гаризаны кабул итү, Электрон Хөкүмәттә теркәү;

лицензиянең гамәлдә булуын туктату турында гаризаны Бүлеккә тапшыру.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар лицензиянең гамәлдә булуын туктату турында гариза кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: лицензиянең гамәлдә булуын туктату турында Бүлеккә карап тикшерүгә җибәрелгән регистрацияләнгән гариза.

3.5.3. Бүлек белгече электрон формада ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша соратулар җибәрә:

юридик затларның Бердәм дәүләт реестрыннан яисә шәхси эшкуарларның Бердәм дәүләт реестрыннан өземтә бирү турында– Федераль салым хезмәтенең Татарстан Республикасы буенча идарәсенә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар алдагы процедураны тәмамлаганнан соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: мәгълүмат бирү турында соратулар.

3.5.4. Ведомствоара электрон хезмәттәшлек системасы аша килгән мөрәҗәгатьләр нигезендә мәгълүмат белән тәэмин итүче белгечләр дәүләт хезмәте күрсәтү өчен сорала торган документларны (мәгълүматны) бирә яисә кирәкле документлар һәм (яисә) мәгълүмат булмау турында хәбәрнамә (алга таба – баш тарту турында хәбәрнамә) җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар законнарда билгеләнгән срокларда җибәрелгән соратулар нигезендә мәгълүмат белән тәэмин итүче тарафыннан гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: Бүлеккә җибәрелгән документлар (белешмәләр) яки баш тарту турында хәбәрнамә.

3.5.5. Бүлек белгече түбәндәгеләрне башкара:

лицензиянең гамәлдә булуын туктату турында гаризаны рәсмиләштерүнең Регламентка 3 нче кушымтада күрсәтелгән форма белән туры килүен тикшерү;

тапшырылган документларны тикшерә һәм документларны кабул итүдән баш тарту өчен Регламентның 2.7 пунктында каралган нигезләрнең булуын (булмавын) билгели.

Регламентның 2.7 пунктындагы 1, 3 пунктчаларында каралган гаризаларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр ачыкланган очракта, Бүлек белгече, сәбәпләрен күрсәтеп, документларны кабул итүдән баш тарту турында хәбәрнамә әзерли (Регламентка 7 нче кушымта), лицензиатка (гариза бирүчегә) тапшыра, яисә тапшыру турында хәбәрнамә белән заказлы почта аша яисә лицензиатның (гариза бирүченең) сайлавы буенча лицензияләүче органның көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ формасында, лицензиатның (гариза бирүченең) мондый хәбәрнамәне алуын раслауны һәм аны илтеп җиткерүне раслауны тәэмин итә торган ысул белән җибәрә.

Регламентның 2.7 пунктындагы 1, 3, 5 пунктчаларында күрсәтелгән документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булмаганда, Бүлек белгече лицензиянең гамәлдә булуын туктату турында боерык проектын әзерли һәм аны Бүлек башлыгына, юридик бүлек башлыгына килештерүгә җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар Регламентның 3.5.3 пунктында каралган процедураны тәмамлаган көннән соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: лицензиянең гамәлдә булуын туктату турында боерык проекты, документларны кабул итүдән баш тарту турында хәбәрнамә.

3.5.6. Бүлек башлыгы, юридик бүлек башлыгы министр урынбасарына имзага җибәрелә торган лицензиянең гамәлдә булуын туктату турында боерык проектын килештерәләр.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар алдагы процедураны тәмамлаганнан соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: министр урынбасарына кул куюга җибәрелгән лицензиянең гамәлдә булуын туктату турында боерыкның килешенгән проекты.

3.5.7. Министр урынбасары лицензиянең гамәлдә булуын туктату турында боерыкка кул куя һәм Бүлек белгеченә җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар алдагы процедураны тәмамлаганнан соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: лицензиянең гамәлдә булуын туктату турында кул куелган боерык.

3.5.8. Бүлек белгече, лицензиянең гамәлдә булуын туктату турында кул куелган боерык нигезендә, лицензияләр реестрына лицензиянең гамәлдә булуын туктату турында язма кертә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар лицензиянең гамәлдә булуын туктату турында боерыкка имза салган көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: лицензиянең гамәлдә булуын туктату турында лицензияләр реестрына кертелгән язма.

3.5.9. Бүлек белгече лицензиянең гамәлдә булуын туктату турында (Регламентка 10 нчы кушымта) язмача хәбәрнамәне лицензиатка бирә яисә аның сайлавы буенча көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә, тапшыру турында хәбәрнамә белән заказлы почта аша кәгазьдә җибәрә.

Гариза бирүче КФҮ гә дәүләт хезмәте сорап мөрәҗәгать иткәндә, КФҮ хезмәткәре гариза бирүчегә кәгазь чыганакта дәүләт хезмәте нәтиҗәсен бирә.

Гариза бирүче Бердәм портал аша мөрәҗәгать иткәндә, автомат рәвештә гариза бирүченең шәхси кабинетына көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсе булган электрон документ җибәрелә.

Лицензиянең гамәлдә булуын туктату турында гаризада лицензиат лицензияләр реестрыннан өземтә алу кирәклеген күрсәткән очракта, лицензияләүче орган Лицензиянең гамәлдә булуын туктату турында хәбәрнамә җибәрү белән бер үк вакытта лицензиатка көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән

имзаланган электрон документ формасында лицензияләр реестрыннан өземтә җибәрә.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура Регламентның 3.5.17 пунктында каралган процедураны тәмамлаган көннән соң өч эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: лицензиянең гамәлдә булуын туктату турында хәбәрнамә, лицензияләр реестрыннан өземтә (кирәк булганда).

3.6. Лицензияләр реестрыннан белешмәләр бирү.

3.6.1. Гариза Министрлыкка шәхсән, ышанычлы зат аша, почта аша, Бердәм портал, КФҮ аша тапшырылырга мөмкин.

Гариза бирүче кәгазь кәгазьдә яисә заказлы почта аша тапшыру турында хәбәрнамә белән, я гади электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә, эш башкару бүлегенә лицензияләр реестрыннан конкрет лицензия турында белешмәләр бирү турында гариза бирә (җибәрә).

КФҮ, КФҮнең читтәге эш урыны аша гариза биргән очракта, КФҮ нең гариза кабул итүче белгече түбәндәгеләрне башкара:

гаризалар һәм документлар кабул итү;

гаризаны теркәү;

гариза тутыруның тулылыгын һәм дөреслеген тикшерү;

гариза бирүчегә гариза җибәрү датасы турында хәбәр итү;

документлар пакетын формалаштыру һәм аны Министрлыкка КФҮ эше Регламентында билгеләнгән тәртиптә җибәрү.

Регламентның әлеге пункты белән билгеләнә торган процедуралар түбәндәгечә гамәлгә ашырыла: Министрлыкка, Бердәм портал аша гариза биргән очракта, гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне; КФҮ, КФҮ нең читтәге эш урыны аша гариза биргәндә, КФҮнең эш регламенты белән билгеләнгән вакытта.

Процедураларның нәтиҗәсе: Министрлыкка җибәрелгән гариза.

3.6.2. Эш башкару бүлеге белгече түбәндәгеләрне башкара:

лицензияләр реестрыннан мәгълүмат бирү турында гаризаны кабул итү, Электрон Хөкүмәттә теркәү;

лицензияләр реестрыннан мәгълүматлар бирү турында гаризаны Бүлеккә тапшыру.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар лицензияләр реестрыннан мәгълүматлар бирү турында гариза кергән көнне гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: лицензияләр реестрыннан мәгълүматлар бирү турында Бүлеккә карап тикшерүгә җибәрелгән регистрацияләнгән гариза.

3.6.3. Бүлек белгече түбәндәгеләрне башкара:

регламентка 4 нче кушымтада күрсәтелгән билгеләнгән форма нигезендә лицензияләр реестрыннан белешмәләр бирү турында гаризаны рәсмиләштерүнең туры килүен тикшерү;

тапшырылган документларны тикшерә һәм документларны кабул итүдән баш тарту өчен Регламентның 2.7 пунктында каралган нигезләрнең булуын (булмавын) билгели.

Регламентның 2.7 пунктындагы 1, 5 пунктчаларында каралган гаризаларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр ачыкланган очракта, Бүлек белгече, сәбәпләрен күрсәтеп, документларны кабул итүдән баш тарту турында хәбәрнамә әзерли (Регламентка 7 нче кушымта), гариза бирүчегә тапшыра, яисә тапшыру турында хәбәрнамә белән заказлы почта аша яисә гариза бирүченең сайлавы буенча Бүлек белгеченең көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзаланган электрон документ формасында, гариза бирүченең мондый хәбәрнамәне алуын раслауны һәм аны илтеп җиткерүне раслауны тәэмин итә торган ысул белән җибәрә.

Регламентның 2.7 пунктының 1, 5 пунктчаларында күрсәтелгән документларны кабул итүдән баш тарту өчен нигезләр булмаганда, Бүлек белгече лицензияләр реестрыннан конкрет лицензия турында өземтә, яисә Министрлыкның кабул ителгән карар турында актының күчермәсен, яисә лицензияләр реестрында лицензияләр турында белешмәләр булмаган яисә конкрет лицензиатны билгеләү мөмкин булмаган очракта бирелә торган соратылган мәгълүматлар булмау турында белешмә.

Электрон документ рәвешендә бирелә торган лицензияләр реестрыннан өземтә Бүлек белгеченең көчәйтелгән квалификацияле электрон имзасы белән имзалана.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедуралар алдагы процедураны тәмамлаганнан соң килә торган ике эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураларның нәтиҗәсе: конкрет лицензия турында лицензияләр реестрыннан өземтә, яисә кабул ителгән карар турында Министрлык актының күчермәсе, йә соратып алына торган белешмәләрнең булмавы турында белешмә, документларны кабул итүдән баш тарту турында хәбәрнамә.

Гариза бирүче КФҮ гә дәүләт хезмәте сорап мөрәҗәгать иткәндә, КФҮ хезмәткәре гариза бирүчегә кәгазь чыганакта дәүләт хезмәте нәтиҗәсен бирә.

Конкрет лицензия турында белешмәләр шулай ук гариза бирүче теләге буенча аңа турыдан-туры тапшырыла, тапшыру турында хәбәрнамә белән заказлы почта аша яки көчәйтелгән квалификацияле электрон имза белән имзаланган электрон документ рәвешендә, лицензияләр реестрыннан өземтә рәвешендә, яисә кабул ителгән карар турында лицензияләүче орган актының күчермәсе, яисә соратып алына торган белешмәләрнең булмавы турында белешмә рәвешендә җибәрелә.

### 3.7. Техник хаталарны төзәтү.

3.7.1. Дәүләт хезмәте нәтиҗәсе булган документта техник хата ачыкланган очракта, гариза бирүче Бүлеккә түбәндәгеләрне тапшыра:

техник хатаны төзәтү турында гариза (Регламентка 11 нче кушымта);

дәүләт хезмәте нәтиҗәсе буларак гариза бирүчегә бирелгән техник хаталы документ;

техник хатаның булуын таныклый торган документлар.

Дәүләт хезмәте нәтиҗәсе булган документта күрсәтелгән белешмәләрдә техник хатаны төзәтү турында гариза гариза бирүче тарафыннан турыдан-туры кәгазьдә яки тапшыру турында хәбәрнамә белән заказлы почта аша, яисә Бердәм портал яки КФҮ аша бирелә.

3.7.2. Документларны кабул итү өчен җаваплы белгеч техник хатаны төзәтү турында гариза кабул итә, кушымта итеп бирелгән документлар белән гаризаны терки һәм аларны Бүлеккә тапшыра.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура гаризаны теркәгәннән соң бер эш көне эчендә гамәлгә ашырыла.

Процедураның нәтиҗәсе: Бүлек белгеченә карап тикшерүгә җибәрелгән кабул ителгән һәм теркәлгән гариза.

3.7.3. Бүлек белгече документларны карый һәм, хезмәт нәтиҗәсе булган документка төзәтмәләр кертү максатларында, гариза бирүчегә төзәтелгән документны шәхсән имза куйдырып бирә яки гариза бирүчегә почта аша юллый.

Әлеге пункт белән билгеләнә торган процедура техник хата ачыкланганнан соң яисә җибәрелгән хата турында теләсә кайсы кызыксынган заттан гариза алганнан соң өч эш көне дәвамында башкарыла.

Процедураның нәтиҗәсе: гариза бирүчегә бирелгән (җибәрелгән) документ.

## 4. Административ регламентның үтәлешен тикшереп тору формалары

4.1. Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча административ процедуралар тарафыннан билгеләнгән гамәлләрнең үтәлешен һәм башкарылуын агымдагы тикшерү дәүләт хезмәте күрсәтү эшен оештыру өчен җаваплы министр (министр урынбасары) тарафыннан башкарыла.

4.2. Агымдагы тикшерү дәүләт хезмәте күрсәтүгә таләпләрне билгели торган Регламент нигезләмәләрен һәм башка норматив хокукый актларны Министрлыкның вазыйфаи затлары тарафыннан үтәү һәм башкаруны тикшерү юлы белән гамәлгә ашырыла.

Административ процедураларның үтәлешен контрольдә тоту формаларына түбәндәге тикшерүләрне үткәрү керә:

эш башкаруны алып бару;

документларны карау нәтиҗәләренең законнар (Регламент) таләпләренә туры килүе;

документларны кабул итү срокларын һәм тәртибен үтәү;

дәүләт хезмәте күрсәткәндә нәтиҗәләр бирү вакытын һәм тәртибен үтәү.

4.3. Үткәрелгән тикшерүләр нәтиҗәләре буенча, дәүләт хезмәтен башкарганда Министрлыкның вазыйфаи затлары тарафыннан җибәрелгән хокук бозулар ачыкланган очракта, гаепле затлар закон нигезендә дисциплинар җаваплылыкка тартыла.

4.4. Гражданнар, аларның берләшмәләре һәм оешмалары тарафыннан Регламентның үтәлешен тикшереп тору Министрлыкка мөрәҗәгатьләр җибәрү юлы белән, шулай ук Регламентны үтәү барышында башкарылган (кабул ителгән) гамәлләргә (гамәл кылмауга) һәм карарларга карата дәүләт хакимиятенең югарырак органнарына шикаять бирү юлы белән гамәлгә ашырыла.

4.5. Дәүләт хезмәте күрсәтүнең тулылыгын һәм сыйфатын тикшерү министрлык актлары нигезендә гамәлгә ашырыла.

Тикшерүләр планлы (Министрлыкның ярты еллык яки еллык эш планнары нигезендә башкарылырга) һәм планнан тыш булырга мөмкин.

5. Дәүләт хезмәте күрсәтүче органның, дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүнең күпфункцияле үзәгенең, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы $1^1$ өлешендә күрсәтелгән оешмаларның, шулай ук аларның вазыйфаи затларының, дәүләт хезмәткәрләрнең, эшчеләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) карата судка кадәр (судтан тыш) шикаять белдерү тәртибе

5.1. Гариза бирүчеләр Министрлыкның, Министрлыкның вазыйфаи затының яисә Министрлыкның дәүләт граждан хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) судка кадәр тәртиптә Министрлыкка шикаять бирергә хокуклы. Дәүләт хезмәте күрсәтүгә бәйле рәвештә министр тарафыннан кабул ителгән карарларга, гамәлләренә (гамәл кылмауга) шикаятьләр Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетына тапшырыла.

КФҮ хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаятьләр – КФҮ җитәкчесенә, КФҮнең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) – КФҮ не гамәлгә куючыга бирелә.

әлеге 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы 11 өлешендә каралган оешмалар хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаятьләр әлеге оешмалар җитәкчеләренә бирелә.

5.2. Гариза бирүче шул исәптән түбәндәге очракларда шикаять белән мөрәҗәгать итә ала:

1) дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза бирүченең соратуын, 210-ФЗ номерлы Федераль законның $15^1$ статьясында күрсәтелгән соратуны теркәү срогын бозу;

2) дәүләт хезмәт күрсәтү срогын бозу.

3) гариза бирүчедән дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында каралмаган документларны яки мәгълүматны бирүне яисә гамәлләр башкаруны таләп итү;

4) гариза бирүчедән дәүләт хезмәте күрсәтү өчен Россия Федерациясе норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы норматив хокукый актларында тапшыру каралган документларны кабул итүдән баш тарту;

5) федераль законнарда һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасы законнарында һәм башка норматив хокукый актларында дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тартуның нигезләре каралмаган булса, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту.

6) дәүләт хезмәте күрсәткәндә гариза бирүчедән Россия Федерациясенең норматив хокукый актларында, Татарстан Республикасының норматив хокукый актларында каралмаган түләү таләп итү;

7) Министрлыкның, Министрлыкның вазыйфаи затының, КФҮ нең, КФҮ хезмәткәренең, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы $1^1$ өлешендә күрсәтелгән оешмаларның, яисә аларның хезмәткәрләренең дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән басма хаталарны һәм хаталарны төзәтүдән баш тартуы яисә мондый төзәтүләрнең билгеләнгән срогын бозуы.

8) дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәләре буенча документлар бирү вакытын яки тәртибен бозу;

9) дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору, әгәр туктатып тору нигезләре федераль законнар һәм алар нигезендә кабул ителгән Россия Федерациясенең бүтән норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы законнары һәм башка норматив хокукый актлары белән каралмаган булса.

10) гариза бирүчедән дәүләт хезмәте күрсәткәндә дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны кабул итүдән беренчел баш тартканда яисә 210-ФЗ номерлы Федераль законның 7 статьясындагы 1 өлешенең 4 пунктында каралган очраклардан тыш, дәүләт хезмәте күрсәткәндә аларның булмавы һәм (яки) дөрес түгеллеге күрсәтелмәгән документлар яисә мәгълүмат таләп итү.

5.3. Шикаять язмача кәгазьдә яки электрон формада бирелә.

Шикаять почта аша, КФҮ аша, «Интернет» челтәре, Министрлыкның рәсми сайты, Бердәм портал аша җибәрелергә мөмкин, шулай ук гариза бирүчене шәхси кабул итү вакытында кабул ителергә мөмкин.

КФҮ, КФҮ хезмәткәренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмауларына) шикаять почта аша, «Интернет» челтәре, КФҮ нең рәсми сайты, Бердәм портал аша җибәрелергә мөмкин, шулай ук гариза бирүчене шәхси кабул итү вакытында кабул ителергә мөмкин.

210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы $1^1$ өлешендә каралган оешмаларның, шулай ук аларның хезмәткәрләренең карарларына һәм гамәлләренә (гамәл кылмавына) карата шикаять почта аша, «Интернет» челтәреннән, әлеге оешмаларның, Бердәм порталның рәсми сайтлары аша җибәрелергә, шулай ук гариза бирүчене шәхсән кабул иткәндә кабул ителергә мөмкин.

5.4. Шикаять аның кергән көненән соң килүче эш көненнән дә соңга калмыйча теркәлергә тиеш.

Министрлыкка, КФҮ гә, КФҮ не гамәлгә куючыга, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы $1^1$ өлешендә каралган оешмаларга яисә югарырак органга кергән шикаять аны теркәгән көннән алып унбиш эш көне эчендә, ә Министрлыкның, КФҮ нең, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы $1^1$ өлешендә каралган оешмаларның Гариза бирүчедән документлар кабул итүдән яисә җибәрелгән басма хаталарны һәм хаталарны төзәтүдән баш тартулары яисә билгеләнгән срокларны бозган өчен шикаять бирелгән очракта – аны теркәгән көннән алып биш эш көне эчендә каралырга тиеш.

5.5. Шикаятьтә түбәндәге мәгълүматлар булырга тиеш:

1) карарлары һәм гамәлләренә (гамәл кылмаулары) нкарата шикаять бирелә торган Министрлыкның, Министрлыкның вазыйфаи затының яки дәүләт хезмәткәренең, КФҮ нең, аның җитәкчесенең һәм (яки) хезмәткәрләренең, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы $1^1$ өлешендә күрсәтелгән оешмаларның, аларның җитәкчеләренең һәм (яки) аларның хезмәткәрләренең исеме;

2) гариза бирүче – физик затның фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта), яшәү урыны турындагы белешмәләр яки гариза бирүче – юридик затның атамасы, урнашкан урыны турындагы белешмәләр, шулай ук элемтә өчен телефон номер(-лар)ы, гариза бирүчегә җавап юлланырга тиешле электрон почта адрес(-лар)ы (булган очракта) һәм почта адресы;

3) Министрлыкның, Министрлыкның вазыйфаи затының яисә дәүләт хезмәткәренең, КФҮнең, КФҮ хезмәткәренең, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы $1^1$ өлешендә каралган оешмаларның, аларның эшчеләренең карары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) турында белешмәләр;

4) гариза бирүче алар нигезендә Министрлыкның, Министрлыкның вазыйфаи затының яисә дәүләт хезмәткәренең, КФҮнең, КФҮ хезмәткәренең, 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы $1^1$ өлешендә каралган оешмаларның, аларның эшчеләренең карары һәм гамәлләре (гамәл кылмавы) белән килешмәвенең дәлилләре Гариза бирүче тарафыннан аның дәлилләрен раслый торган документлар (булган очракта) яисә аларның күчермәләре тапшырылырга мөмкин.

5.6. Шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре буенча түбәндәге карарларның берсе кабул ителә:

1) шикаять канәгатьләндерелә, шул исәптән кабул ителгән карарны гамәлдән чыгару, дәүләт хезмәте күрсәтү нәтиҗәсендә бирелгән документларда җибәрелгән хаталарны һәм ялгышларны төзәтү, Россия Федерациясе норматив хокукый актлары, Татарстан Республикасы норматив хокукый актлары белән түләү алу каралмаган очракларда алынган акчаны гариза бирүчегә кире кайтару рәвешендә дә;

2) шикаятьне канәгатьләндерү кире кагыла.

Әлеге пунктта күрсәтелгән карар кабул ителгән көннән соң килә торган көннән дә соңга калмыйча, гариза бирүчегә язма рәвештә һәм гариза бирүче теләге буенча электрон рәвештә шикаятьне карап тикшерү нәтиҗәләре турында дәлилләнгән җавап юллана.

5.7. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш дип танылган очракта, Регламентның 5.6 пунктында күрсәтелгән җавапта гариза бирүчегә, дәүләт хезмәте күрсәткәндә ачыкланган җитешсезлекләрне кичекмәстән бетерү максатларында, дәүләт хезмәте күрсәтүче орган, КФҮ йә 210-ФЗ номерлы Федераль законның 16 статьясындагы $1^1$ өлешендә каралган оешма тарафыннан гамәлгә ашырыла торган гамәлләр турында мәгълүмат бирелә, шулай ук китерелгән уңайсызлыклар өчен гафу үтенелә, гариза бирүчегә дәүләт хезмәте алу максатларында башкарырга кирәк булган алдагы гамәлләре турында мәгълүмат күрсәтелә.

5.8. Шикаять канәгатьләндерелергә тиеш түгел дип табылган очракта, гариза бирүчегә җибәрелә торган Регламентның 5.6 пунктында күрсәтелгән җавапта кабул ителгән карарның сәбәпләре турында нигезле аңлатмалар, шулай ук кабул ителгән карарга карата шикаять бирү тәртибе турында мәгълүмат китерелә.

5.9. Шикаятьне карап тикшерү барышында яки аның нәтиҗәләре буенча административ хокук бозу яки җинаять билгеләре ачыкланган очракта, шикаятьләрне карап тикшерү буенча вәкаләтле вазыйфаи зат, хезмәткәр, булган материалларны, кичекмәстән, прокуратура органнарына җибәрә.

Кара һәм төсле металл калдыкларын әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату эшчәнлеген лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең Административ регламентына 1 нче кушымта

Форма

Кара металл һәм төсле металл калдыкларын әзерләүгә, саклауга, эшкәртүгә һәм сатуга лицензия бирү турында
ГАРИЗА

______________________________________________________________________

(тулы һәм (булган очракта) кыскартылган исеме, шул исәптән фирма исеме, һәм оештыру-хокукый формасы – юридик зат өчен; фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта ), шәхесне раслый торган документ белешмәләре – шәхси эшкуар өчен)

кара металл һәм төсле металл калдыкларын әзерләүгә, саклауга, эшкәртүгә һәм сатуга лицензия бирүегезне сорыйм.

эшләр төре (лицензияләнгән эшчәнлек төре составында башкарыла торган эш төрен (төрләрен) сайлап алырга)

☐ кара металл калдыкларын әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату

☐ төсле металл калдыкларын әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату

☐ төсле металл калдыкларын әзерләү, саклау, сату

Юридик затның урнашу урыны адресы (шәхси эшкуарның яшәү урыны адресы) ______________________________________________________________________

Язышу өчен адрес ______________________________________________________________________
(почта адресы, электрон почта адресы, элемтә өчен телефон)

Лицензияләнә торган эшчәнлек төрен гамәлгә ашыру урыннарының адреслары ______________________________

Дәүләт теркәвенә алу турындагы язманың төп дәүләт теркәү номеры ______________________________________________________________________
(ОГРН – юридик зат өчен, ОГРНИП – шәхси эшкуар өчен)

Юридик затларның (шәхси эшкуарларның) бердәм дәүләт реестрына мәгълүматлар кертү фактын раслый торган документ белешмәләре ____________________________________

Салым түләүченең идентификацион номеры (ИНН) _____________________________;

Салым органында юридик затны (шәхси эшкуарны) исәпкә кую фактын раслый торган документ белешмәләре _____________________________________________

Күчемсез милекнең Бердәм дәүләт реестрында хокуклар теркәлгән, Лицензияләнә торган эшчәнлек алып бару өчен кирәкле һәм милек хокукында яки башка законлы нигездә юридик затка (шәхси эшкуарга) караган җир кишәрлекләре, биналар, төзелмәләр, корылмалар һәм помещениеләр (биналарның, төзелмәләрнең, корылмаларның һәм помещениеләрнең бердәм

аерымланган өлеше) турында белешмәләр

______________________________________________________________________________

Лицензияләү мәсьәләләре буенча вәкаләтле хезмәткәр ______________________________________
(вазыйфасының атамасы, ФИА ( соңгысы – булганда), телефоны)

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының кара металл һәм төсле металл калдыкларын әзерләүгә, саклауга, эшкәртүгә һәм сатуга лицензияләр реестрыннан өземтә бирү кирәклеге турында белешмәләр

☐ лицензияләр реестрыннан өземтә кирәк, җибәрү өчен электрон почта адресы ______

☐ лицензияләр реестрыннан өземтә кирәк түгел

Юридик затның җитәкчесе
(шәхси эшкуар) ________________________ __________________________
(имза, мөһер) (ФИА (соңгысы булганда))

Искәрмә. Мөһер – булганда

☐ Аңа имза салынган көннән алып язма рәвештә кире алу көненә кадәр (шәхси эшкуарлар өчен) шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә килешәм _________________________________
(ФИА (соңгысы булганда), имза)

Кара һәм төсле металл калдыкларын әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату эшчәнлеген лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең Административ регламентына 2 нче кушымта

Форма

Лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында
ГАРИЗА

юридик зат яисә шәхси эшкуар тарафыннан лицензияләнгән эшчәнлек төрен башкару урыны адресы, лицензияләнгән эшчәнлек төрен тәшкил итә торган башкарыла торган эшләр исемлеге үзгәргән, үзгәртеп кору, кушылу, лицензиатны башка юридик затка кушу формасында юридик затны яңадан оештырганда, аның исеме, урнашкан урыны үзгәргән, шәхси эшмәкәрнең яшәү урыны, исеме, фамилиясе һәм әтисенең исеме (булган очракта), шәхесен раслый торган документ реквизитлары үзгәргән очракта, лицензияләнгән эшчәнлек төрен алып баруның аерым адреслары буенча эшчәнлек туктатылган очракларда)

Лицензияләр реестрына ______________________________________________ кара металл һәм төсле металл калдыкларын әзерләүгә, саклауга, эшкәртүгә һәм сатуга лицензиягә карата үзгәрешләр кертүегезне сорыйм _____________________________________
(лицензиянең теркәү номеры, лицензия бирү датасы)

Лицензиат: _________________________________________________________________________
(тулы һәм (булган очракта) кыскартылган исеме, шул исәптән фирма исеме, һәм оештыру-хокукый формасы – юридик зат өчен; фамилиясе, исеме, атасының исеме (соңгысы – булган очракта ), шәхесне раслый торган документ белешмәләре – шәхси эшкуар өчен)

Юридик затның урнашу урыны адресы (шәхси эшкуарның яшәү урыны адресы) __________________________________________________________________

Язышу өчен адрес __________________________________________________________________
(почта адресы, электрон почта адресы, элемтә өчен телефон)

Дәүләт теркәвенә алу турындагы язманың төп дәүләт теркәү номеры ___________________________________________________________________________________
(ОГРН – юридик зат өчен, ОГРНИП – шәхси эшкуар өчен)

Юридик затларның (шәхси эшкуарларның) бердәм дәүләт реестрына мәгълүматлар кертү фактын раслый торган документ белешмәләре ___________________________________

Салым түләүченең идентификацион номеры (ИНН) ____________________________;

Салым органында юридик затны (шәхси эшкуарны) исәпкә кую фактын раслый торган документ белешмәләре ____________________________________________

___________________________________________________________________________бәйле рәвештә
(лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү сәбәбен күрсәтергә: яңа объектны ачу, объект эшчәнлеген туктату, эш төрен өстәү (төшереп калдыру), үзгәртеп кору, кушылу, лицензиатны башка юридик затка кушу формасында юридик затны яңадан оештырганда, аның исеме, урнашкан урыны үзгәргән, шәхси эшмәкәрнең яшәү урыны, исеме, фамилиясе һәм әтисенең исеме (булган очракта), шәхесен раслый торган документ реквизитлары үзгәрү)

Аларга карата лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертергә кирәкле лицензияләнгән эшчәнлек төрен гамәлгә ашыру урыннарының адреслары __________________________________________

Эшләр төре (лицензияләнгән эшчәнлек төре составында башкарыла торган эш төрен (төрләрен) сайлап алырга)

☐ кара металл калдыкларын әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату

☐ төсле металл калдыкларын әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату

☐ төсле металл калдыкларын әзерләү, саклау, сату

Күчемсез милекнең Бердәм дәүләт реестрында хокуклар теркәлгән, Лицензияләнә торган эшчәнлек алып бару өчен кирәкле һәм милек хокукында яки башка законлы нигездә юридик затка (шәхси эшкуарга) караган җир кишәрлекләре, биналар, төзелмәләр, корылмалар һәм помещениеләр (биналарның, төзелмәләрнең, корылмаларның һәм помещениеләрнең бердәм аерымланган өлеше) турында белешмәләр

_______________________________________________________________________________

Лицензияләү мәсьәләләре буенча вәкаләтле хезмәткәр ____________________________________
(вазыйфасының атамасы, ФИА ( соңгысы – булганда), телефоны)

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының кара металл һәм төсле металл калдыкларын әзерләүгә, саклауга, эшкәртүгә һәм сатуга лицензияләр реестрыннан өземтә бирү кирәклеге турында белешмәләр

☐ лицензияләр реестрыннан өземтә кирәк, җибәрү өчен электрон почта адресы ______

☐ лицензияләр реестрыннан өземтә кирәк түгел

Юридик затның җитәкчесе
(шәхси эшкуар) ________________________ __________________________
(имза, мөһер) (ФИА (соңгысы булганда))

Искәрмә. Мөһер – булганда

☐ Аңа имза салынган көннән алып язма рәвештә кире алу көненә кадәр (шәхси эшкуарлар өчен) шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә килешәм ________________________________
(ФИА (соңгысы булганда), имза)

Кара һәм төсле металл калдыкларын әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату эшчәнлеген лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең Административ регламентына 3 нче кушымта

Форма

Лицензиянең гамәлдә булуын туктату турында ГАРИЗА

Кара металл һәм төсле металл калдыкларын әзерләүгә, саклауга, эшкәртүгә һәм сатуга лицензиянең гамәлдә булуын туктатуны сорыйм ______________________________________________________________________
(лицензиянең теркәү номеры, лицензия бирү датасы)

Юридик затның (шәхси эшкуарның) исеме ____________________

Юридик затның урнашу урыны адресы (шәхси эшкуарның яшәү урыны адресы) ______________________________________________________________

Язышу өчен адрес _____________________________________________________________
(почта адресы, электрон почта адресы, элемтә өчен телефон)

Дәүләт теркәвенә алу турындагы язманың төп дәүләт теркәү номеры ______________________________________________________________________
(ОГРН – юридик зат өчен, ОГРНИП – шәхси эшкуар өчен)

Юридик затларның (шәхси эшкуарларның) бердәм дәүләт реестрына мәгълүматлар кертү фактын раслый торган документ белешмәләре __________________________________

Салым түләүченең идентификацион номеры (ИНН) ____________________________;

Салым органында юридик затны (шәхси эшкуарны) исәпкә кую фактын раслый торган документ белешмәләре ___________________________________________

Лицензияләү мәсьәләләре буенча вәкаләтле хезмәткәр ________________________________
(вазыйфасының атамасы, ФИА ( соңгысы – булганда), телефоны)

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының кара металл һәм төсле металл калдыкларын әзерләүгә, саклауга, эшкәртүгә һәм сатуга лицензияләр реестрыннан өземтә бирү кирәклеге турында белешмәләр

☐ лицензияләр реестрыннан өземтә кирәк, җибәрү өчен электрон почта адресы ______

☐ лицензияләр реестрыннан өземтә кирәк түгел

Юридик затның җитәкчесе
(шәхси эшкуар) ______________________ ________________________
(имза, булса – мөһер) (ФИА (соңгысы булганда))

Искәрмә. Мөһер – булганда

☐ Аңа имза салынган көннән алып язма рәвештә кире алу көненә кадәр (шәхси эшкуарлар өчен) шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә килешәм ______________________________
(ФИА (соңгысы булганда), имза)

Кара һәм төсле металл калдыкларын әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату эшчәнлеген лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең Административ регламентына 4 нче кушымта

Форма

Лицензияләр реестрыннан белешмәләр бирү турында ГАРИЗА

_______________________________________________ лицензия турында
(лицензиянең теркәү номерын, лицензия бирү датасын күрсәтергә)

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгының кара һәм төсле металл калдыкларын әзерләүгә, саклау, эшкәртү һәм сатуга лицензияләр реестрыннан электрон документ формасында, аларны электрон почта адресына юллап ________________________________________, мәгълүмат бирүегезне сорыйм.

Гариза бирүче ____________________________________________ ________________________________
(имза, булса – мөһер) (ФИА (соңгысы булганда))

☐ Аңа имза салынган көннән алып язма рәвештә кире алу көненә кадәр (шәхси эшкуарлар, физик затлар өчен) шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә килешәм

___________________________________
(ФИА (соңгысы булганда), имза)

Кара һәм төсле металл калдыкларын әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату эшчәнлеген лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең Административ регламентына 5 нче кушымта

____________________________________

(ЮЗ/ИП атамасы, ИНН, ОГРН/ОГРНИП)

**Ачыкланган җитешсезлекләрне бетерү һәм (яки) булмаган документларны тапшыру зарурлыгы турында хәбәрнамә**

«Эшчәнлекнең аерым төрләрен лицензияләү турында» 2011 елның 4 маендагы 99-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Сезгә _____ ______ ____ номерлы ______________________________________________турында гаризагызның _______________________________________________________________________________________

(хокук бозуларны күрсәтергә)

бәйле рәвештә карауга кабул ителмәве хакында хәбәр итәбез

Сезнең тарафтан ачыкланган бозулар гариза кабул ителгән көннән утыз көн эчендә бетерелгән очракта, Сезнең гариза каралуга кабул ителәчәк, югыйсә утыз көнлек сроктан соң гаризага теркәлгән документлар Сезгә кире кайтарылачак.

Министр урынбасары _______________________________

(Ф.И.А.)

Кара һәм төсле металл калдыкларын әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату эшчәнлеген лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең Административ регламентына 6 нчы кушымта

______________________________

(ЮЗ/ИП атамасы, ИНН, ОГРН/ОГРНИП)

**Лицензия бирү турында (лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында) тапшырылган гаризаны һәм аңа кушып бирелә торган документларны кире кайтару турында хәбәрнамә**

«Эшчәнлекнең аерым төрләрен лицензияләү турында» гы 2011 елның 4 маендагы 99-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә ______ ______ ____ номерлы __________ турында гариза билгеләнгән форманы бозып рәсмиләштерелгән һәм (яки) документлар тулы күләмдә тапшырылмаган булуга бәйле рәвештә , Сезгә утыз көн эчендә ачыкланган җитешсезлекләрне бетерү һәм (яки) булмаган документларны тапшыру кирәклеге турында хәбәрнамә җибәрелде.

Лицензиягә дәгъва кылучы (лицензиат) утыз көн эчендә ачыкланган җитешсезлекләрне бетерү һәм (яки) булмаган документларны тапшыру кирәклеге турында хәбәрнамә алганнан соң 30 көн эчендә ____________ турында тиешле рәвештә рәсмиләштерелгән гаризаны һәм (яки) аңа беркетелеп бирелә торган документларны тулы күләмдә тапшырмаган очракта, моңа кадәр бирелгән гариза һәм аңа кушып бирелә торган документлар лицензиягә дәгъва кылучыга (лицензиатка) кире кайтарылырга тиеш.

Билгеләнгән вакытка Сезнең тарафтан тиешле рәвештә рәсмиләштерелгән гариза һәм (яки) аңа беркетелеп бирелә торган документлар тулы күләмдә тапшырылмаганга бәйле рәвештә, элек Сез тапшырган ______ ____ номерлы __________ турында гариза һәм аңа беркетелеп бирелә торган документлар кире кайтарыла.

Министр урынбасары ____________________________

(Ф.И.А.)

Кара һәм төсле металл калдыкларын әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату эшчәнлеген лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең Административ регламентына 7 нче кушымта

______________________________
(ФИА (соңгысы булган очракта), ЮЗ/ИП атамасы, ИНН, ОГРН/ОГРНИП)

**Документлар кабул итүдән баш тарту турында хәбәрнамә**

«Эшчәнлекнең аерым төрләрен лицензияләү турында» гы 2011 елның 4 маендагы 99-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Сезгә хәбәр итәбез: _____ елның ___________ _____ номерлы гариза

____________________________________________________________________________________________
(нәрсәгә бәйле рәвештә гариза бирелүен күрсәтергә)

______________________________________________ бәйле рәвештә, карауга кабул ителмәде.
(хокук бозуларны күрсәтергә)

Министр урынбасары ___________________________
(Ф.И.А.)

Кара һәм төсле металл калдыкларын әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату эшчәнлеген лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең Административ регламентына 8 нче кушымта

____________________________________
(ЮЗ/ИП атамасы, ИНН, ОГРН/ОГРНИП)

**Лицензия бирү (лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында) турында хәбәрнамә**

«Эшчәнлекнең аерым төрләрен лицензияләү турында» гы 2011 елның 4 маендагы 99-ФЗ номерлы Федераль законның 14 статьясындагы 5 өлеше нигезендә Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы Сезнең ____ елның _________ ______ номерлы ____________ турында гаризагыз буенча Министрлыкның _______ елның ______ елның ________ ____ номерлы боерыгы белән ________________________ турында карар кабул ителүен хәбәр итә.

Министр урынбасары ___________________________
(Ф.И.А.)

Кара һәм төсле металл калдыкларын әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату эшчәнлеген лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең Административ регламентына 9 нчы кушымта

______________________________
(ЮЗ/ИП атамасы, ИНН, ОГРН/ОГРНИП)

**Лицензия бирүдән баш тарту (лицензияләр реестрына үзгәрешләр кертү турында) турында белдерү**

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы белдерүенчә, Сезнең _______ _________ ______ номерлы ____________ турында гаризагыз буенча Министрлыкның _______ елның ______________ ____ номерлы боерыгы белән «Эшчәнлекнең аерым төрләрен лицензияләү турында» 2011 елның 04 маендагы 99-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә ___________________ баш тарту турында карар кабул ителде.

Баш тарту нигезләре:
_____________________________________________________________________

Министр урынбасары

___________________________
(Ф.И.А.)

Кара һәм төсле металл калдыкларын әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату эшчәнлеген лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең Административ регламентына 10 нчы кушымта

______________________________
(ЮЗ/ИП атамасы, ИНН, ОГРН/ОГРНИП)

**Лицензиянең гамәлдә булуын туктату турында хәбәрнамә**

«Эшчәнлекнең аерым төрләрен лицензияләү турында» гы 2011 елның 4 маендагы 99-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы Сезнең ____ елның _________ ______ номерлы ____________ турында гаризагыз буенча Министрлыкның _______ елның ______ елның ________ ____ номерлы боерыгы белән ________________________ лицензияне 20__ елның «____»______ туктату гамәлен тану турында карар кабул ителүен хәбәр итә.

(лицензиянең теркәү номеры, лицензия бирү датасы)

кара металл һәм төсле металл калдыкларын әзерләүгә, саклауга, эшкәртүгә һәм сатуга.

Министр урынбасары ___________________________
(Ф.И.А.)

Кара һәм төсле металл калдыкларын әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату эшчәнлеген лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең Административ регламентына 11 нче кушымта

Техник хатаны төзәтү турында ГАРИЗА

Кара металл һәм төсле металл калдыкларын әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату эшчәнлеген лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәткәндә җибәрелгән техник хатаны төзәтүегезне сорыйм

Хаталар тасвирламасы: ____________________________________________________________

Түбәндәге документларны терким:
1.
2.
3.

Лицензияләү мәсьәләләре буенча вәкаләтле хезмәткәр ______________________________________
(вазыйфасының атамасы, ФИА ( соңгысы – булганда), телефоны)

Юридик затның җитәкчесе
(шәхси эшкуар) __________________________ ____________________________
(имза, мөһер) (ФИА (соңгысы булганда))

Искәрмә. Мөһер – булганда

☐ Аңа имза салынган көннән алып язма рәвештә кире алу көненә кадәр (шәхси эшкуарлар өчен) шәхси мәгълүматларны эшкәртүгә килешәм ____________________________________
(ФИА (соңгысы булганда), имза)

Кара һәм төсле металл калдыкларын әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату эшчәнлеген лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең Административ регламентына кушымта (белешмәлек)

Кара металл һәм төсле металл калдыкларын әзерләү, саклау, эшкәртү һәм сату эшчәнлеген лицензияләү буенча дәүләт хезмәте күрсәтүгә җаваплы һәм аны бирүне контрольдә тотучы органнар һәм вазыйфаи затлар реквизитлары

Татарстан Республикасы Икътисад министрлыгы

| Вазыйфасы | Телефоны | Электрон адресы |
|---|---|---|
| Министр | 524-91-11 | me.rt@tatar.ru |
| Министр урынбасары | 524-91-05 | Kondratova.Natalya @tatar.ru |
| Лицензияләү бүлеге башлыгы | 524-91-48 | Nadezhda.Gornovskaya @tatar.ru |
| Лицензияләү бүлегенең әйдәп баручы киңәшчесе | 524-91-49 | L.Safin@tatar.ru |
| Лицензияләү бүлегенең әйдәп баручы белгече | 524-90-22 | Hasanova.Elmira@tatar.ru |
| Эш башкару бүлеге башлыгы | 524-91-68 | Ramziya.Zimina@tatar.ru |

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты

| Вазыйфасы | Телефоны | Электрон адресы |
|---|---|---|
| Сәнәгать бүлеге башлыгы | 264-76-74 | German.Fashiev@tatar.ru |